Җәмәгать, мин – исән!

Шатлыгым белән уртаклашасым килә. Нинди зольмәттән чыгуымны белгертү өчен, Казан онкология үзәгендә дәвалануымны әйтүем дә җитәр кебек. Мин хастаханәгә дүшәмбе көнне кердем һәм шул ук атнаның җомгасында, скальпель кискән җөйләргә соңгы тапкыр перевязка ясатып, өйгә кайтып киттем. Марля тампоннарын куйганда, шәфкать туташының: «Бу – ювелир эше!» – дип, хирургны мактавы истә калды. «Ювелир» дигәнебез – операция ясаучы хирург, медицина фәннәре докторы профессор Михаил Бурмистров.

6 БИТ

Ташламалы бәядән языл!

11-21 май, 2017

Абунәче декадасы

П2430 индексы (пәнҗешәмбе саны) – 415 сум 86 тиен

П2395 индексы (атнага өч тапкыр)– 854 сум 28 тиен

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 12.05.2017 | № 50 (5812)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

МЕҢӘ ИЧМАСАМ ТАТАРСТАН ЮЛЛАРЫ ДИСЕННӘР

«Шәһри Казан» редакциясе бу көннәрдә тракторлар гөрелтесе астында эшләп ята, чөнки Чистай урамы юлын капиталь төзекләндерү бара. Иҗат эшенә комачаулыйлар дип зарлану уйда да юк. Киресенчә, үзебез тракторга утырырга, кулга көрәк алырга әзер булып утыру. Ни дисәң дә, тиздән зур вакыйгалар көтелә бит.

КАПИТАЛЬ РЕМОНТ

Автор фотолары

Дамир БӘДРИЕВ

Казанда 18-28 июньнәрдә «Казан-Арена» футбол стадионында Конфедерация кубогы матчы уеннары узачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов матчта катнашачак спортчылар һәм куначклар узачак урамнардагы юлларны шәхсән үзе карап чыкты. Аны Татарстан премьер-министры Алексей Песошин, Казан мэры Илсур Метшин, республиканың төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин, транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин озатып йөрде. Конфедерация кубогы матчына әзерлек кысаларында «Миллениум» күпере, Әмирхан, Бондаренко, Чистай, Вахитов, Краснококшайск урамнары юллары төзекләндерелә.

Казанда әле 26 майда Евразия икътисади берлеге хөкүмәтләре башлыклары һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре хөкүмәтләре башлыклары советы узачак. Татарстан Президенты шушы дәрәҗәле киңәшмәдә катнашучылар узачак урамнарны да күздән кичерде. Болар: Оренбург тракты, Университет проспекты, Мәүлетов урамы (Академик Парин урамы белән кисешкән өлеше), Тихомирнов, Пушкин, Горький, Карл Маркс, Островский, Назарбаев урамнары (Сәлимҗанов урамыннан Вишневский урамына кадәрге өлеше).

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанның Кабан күле ярларын төзекләндерү эшләренең һаман башланмавын кискен тәнкыйтьләгән иде. «Кабан күлен төзекләндерүгә акча билгеләнде, ә эш юк. Мин бу хәлдә йоклый алмас идем», – дигән иде ул. Казан урамнары юлларын караганнан соң, Президент Рөстәм Миңнеханов Кабан күленә туктады. Президент ярдәмчесе Наталия Фишман күлнең Меңьеллык паркы каршындагы һәм Һади Такташ урамындагы спорт комплексы янындагы яр буйларын төзекләндерү проектлары белән таныштырды.

Башкалада бу җәйдә 33 урам юлы, 180 ишегалды, 30 квартал эчке юллары яңартылачак. Шушы эшләрне башкару өчен, «Имин һәм сыйфатлы юллар» федераль проекты кысаларында, 2 миллиард сум тәгаенләнгән. Аның 1,2 миллиард сумы – федераль, ә 800 миллион сумы – республика бюджетыннан.

→ Ахыры 2нче биттә.

Хөкүмәтнең чираттагы кәнәфиенә хуҗа табылды

СЕССИЯ

prav.tatarstan.ru

Дәүләт Советының апрель аенда узган утырышында премьер-министр вазифасына Алексей Песошинны расласалар, бер ай эчендә ул, үзенә беренче урынбасар табып, кичә бу урынга депутатлар Рөстәм Нигъмәтуллины билгеләде. Сүз уңаеннан, Песошин белән Нигъмәтуллинның икесе дә – Казан мэры Илсур Метшин командасыннан.

Линар ЗАКИРОВ

ЯҢА ПРЕМЬЕРНЫҢ ЯҢА УРЫНБАСАРЫ

Алексей Песошин үз урынбасары урынына Рөстәм Нигъмәтуллинны тәкъдим иткәндә, аның Казан шәһәре башлыгы вазифасында җир һәм мөлкәти мәсьәләләр, транспорт юнәлешен, гадәттән тыш хәлләр комиссиясен җитәкләве турында әйтте.

– Рөстәм Камил улы үзен эшенең остасы буларак танытты. Казанда узган җәйге Универсиадага, дөньякүләм башка төрле спорт һәм иҗтимагый чараларны оештыруга зур өлеш кертте, – диде республиканың хөкүмәт башлыгы.

Рөстәм Нигъмәтуллинның эшләре, яңа кәнәфигә күчеп утыргач, билгеле, бермә-бер артачак. Ул, Алексей Песошин ялга китеп торганда, аны алыштырырга тиеш булачак, моннан тыш, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, хокук бозуларны булдырмау, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, экология һәм башка мәсьәләләр аның җилкәсенә йөкләнә. Сүз уңаеннан, Алексей Песошин премьер-министр булганчы, үзе дә республика хөкүмәте башлыгының беренче урынбасары вазифасында тир түкте.

КПРФ фракциясе җитәкчесе Хафиз Миргалимов, трибуна янына чыгып, табадан төшкән вице-премьерга теләкләрен дә ирештерде. Аның әйтүенчә, социаль мәсьәләләрне чишүгә тагы да күбрәк игътибар бирергә кирәк.

Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Рөстәм Нигъмәтуллиннан: «Әйтер сүзегез бармы?» – дип сорагач, вице-премьер никтер трибуна янына чыгудан баш тартты...

«ҖИР КОДЕКСЫ» «ТАТФОНДБАНК» КЕРТЕМЧЕЛӘРЕНӘ ЯРДӘМГӘ КИЛӘ

Төпкә киткән «Татфондбанк» мәсьәләсе Дәүсовет утырышында кабат калкып чыкты. Бу юлы депутатлар, нишләргә икән дип, аһ-ваһ килмәде, ә республиканың Җир кодексына үзгәрешләр кертеп, акчалары банкта «янган» кертемчеләргә һәм алданган өлешләп төзүчеләргә ярдәм күрсәтү чаралары каралган закон проектын кабул иттеләр.

Татарстанның җир һәм мөлкәти мәсьәләләре министры Азат Хамаев әйтүенчә, Җир кодексында җирне эре инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен сатулашуларсыз гына бирү очрагы каралган. Әмма мондый очракның берничә критерие бар. Депутатларның хәер-фатихасы белән, критерийлар исемлегенә бөлгенлеккә чыккан банклардан һәм намуссыз төзүчеләрдән зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү чарасы каралган тагын бер пункт өстәлде.

– Социаль яктан әһәмиятле булган проектларны тормышка ашырудан кергән акчаның бер өлеше югарыда телгә алынган гражданнарга юлланыр дип торабыз, – диде Азат Хамаев.

Әле берничә атна элек кенә Рөстәм Миңнеханов, Россия Президенты Владимир Путин белән очрашканда, махсус фонд төзелүе турында хәбәр итте. Коммерция нигезендә бирелгән җирләрдән кергән акчаның бөлгенлеккә чыккан банклардан һәм намуссыз төзүчеләрдән зыян күрүчеләргә җибәрелүе турында әйтелде. Һәрхәлдә, ярдәм күрсәтү юллары югары даирәдә әлегә уйланыла.

ИСЕРЕКЛӘР ТАБИБЛАРНЫ ТЫНГЫСЫЗЛАУДАН КАЙЧАН ТУКТАР?

Айнныткычлар кире кайтырга мөмкин. Депутатлар шул хактагы закон проектын беренче укылышта кабул итте. Татарстанның сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Сергей Осипов аңлатканча, айнныткычларны республиканың 11 җирлегендә ачарга ниятлиләр: Казанда, Чаллыда, Азнакайда, Әлмәттә, Бөгелмәдә, Алабугада, Зәйдә, Яшел Үзәндә, Лениногорскида, Түбән Камада һәм Чистайда. Бу районнар Россия Эчке эшләр органнары системасында республикада 2012 елга кадәр гамәлдә булган айныткычлар схемасы нигезендә сайланылган. Закон үз көченә кергәнче, икенче һәм өченче укылышта каралырга тиеш.

Хәтерләсәгез, 2012 елга кадәр айныткычлар эчке эшләр органнары карамагында иде. Шуннан соң алар Эчке эшләр министрлыгы системасыннан чыгып, исерекләрне хастаханәләргә илтә башладылар. Әмма кайберләре медицина ярдәменә мохтаҗ булмыйча, айныр өчен аларга черем итеп алырга гына кирәк иде. Җитмәсә, кайбер сәрхушләр табибларны һәм хастаханәдә дәваланучыларны тынгысызлап, кул күтәрүгә барып җиткән очраклар да шактый. Әгәр закон кабул ителсә, ак халатлы фәрештәләр җиңелрәк сулап куяр иде, мөгаен...

Торак кыйммәтләнә

Россиянең Төзелеш министрлыгы быелның II кварталына Россия субъектларында социаль ипотека программасы буенча төзелгән торакларның уртача квадрат метры бәясен билгеләде. Нәтиҗәдә, торак азмы-күпме кыйммәтләнде. Татарстанда социаль ипотека программасы буенча тапшырыла торган фатирларның квадрат метры бәясе моңа кадәр 35 079 сум булса, хәзер ул 35 289 сумга җитте.

Сүз уңаеннан, иң кыйммәтле торак – Мәскәүдә (квадрат метры 90 400 сум), иң арзаны Калмыкия Республикасында (квадрат метры 25 351 сум) тәшкил итә, дип яза ТатСентер.ру.

Менә ичмасам Татарстан юллары дисеннәр

→ Ахыры. Башы 1нче биттә.

Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – тышкы төзекләндерү комитеты рәисе Игорь Куляжев әйткәнчә, башкаланың муниципаль юл фондыннан 94 миллион сум бүленгән. Төзекләндерү исемлегендә Ибраһимов проспекты, Копылов, Маршал Чуйков, Восстание, Тукай, Миль, Даурия, Танк, Нариманов урамнары юллары бар. Урам юлларын төзекләндергәндә 320 юл билгесе дә яңартыла, гомум озынлыкта өч километр тимер рәшәткә урнаштырыла. Ишегалларын комплекслы төзекләндерү быел Академик Павлов, Голубятников, Дубравная, Блюхер, Восход, Минск урамнарында, Себер трактында үткәреләчәк.

Ишегаллары юллары киңәйтелә, 3 мең машинага «кесә», ягъни куеп тору урыны ясала. Ишегалларын төзекләндергәндә, «Мөмкинлекле мохит» программасы буенча физик мөмкинлекләре чикле кешеләр мәнфәгатьләре, шулай ук казанлыларның фикерләре исәпкә алына. Мәсәлән, машина урыны ясаганда яки ишегалды юлын киңәйткәндә, кайбер агачларны кисәргә туры килә. Менә шушында кайчак кызу бәхәсләр куба. Өлкәннәргә – яшеллек, ә яшьләргә машина урыны кирәк. Шөкер, ике якны да канәгатьләндергән чишелеш табыла үзе. Киселгән агачлар урынына яңа үсентеләр утыртыла.

Казанда 2011 елдан башлап инде 1625 ишегалды, 10 миллион квадрат метр юл өслеге, 36 бистәдә 263 урам юлы төзекләнделде.

ТРАНСПОРТ

Мәскәүгә өч сәгать ярымда?

Мәскәү–Казан югары тизлекле магистральне 2022 елга кадәр үк файдалануга тапшыру ниятләнелә.

Магистраль төзелеше уңаеннан, Казанда җәмәгать тыңлаулары оештырылачак. Казанлылар бу уңайдан үзләренең фикерләрен әйтә ала. Тема – Югарытизлекле магистральнең тирә-юнь мохиткә тәэсире. Материаллар белән «Скоростные магистрали» сайтында һәм мэрия порталында алдан ук танышырга була. Казанда документларны «Казан-2» тимер юл вокзалы бинасында да карарга мөмкин. Кабул итүләр 14 майдан 13 июньгә кадәр 10.00-18.00 сәгатьләрдә үткәреләчәк.

Җәмәгать тыңлаулары «Казан» милли мәдәният үзәгендә 14 июньдә 16.00 сәгатькә билгеләнгән. Җәмәгать тыңлауларыннан соң казанлылар үзләренең тәкъдимнәрен **ovosvsm@mosgiprotrans.ru** электрон почтасына җибәрә ала.

Мәскәү–Казан югарытизлекле магистраленең озынлыгы 770 километрны тәшкил итәчәк. Магистральдә 50-70 километр саен тукталыш исәпләнелгән. Казаннан Мәскәүгә өч сәгать ярымда барып җитеп булачак. Хәзергә гадәти поездларда моның өчен 14 сәгать вакыт кирәк. Проектны гамәлгә ашыруда Кытай да катнашачак. Киләчәктә Мәскәү–Казан трассасы Мәскәү–Пекин югарытизлекле магистральнең бер өлеше булыр дип фаразланыла.

Мәктәпләрдә соңгы кыңгырау чыңларга да санаулы көннәр генә калып бара. Балаларның җәйге ялын файдалырак һәм кызыклырак итү турында өлкәннәр күптән баш вата. «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә сүз шул хакта барды.

Әйдаманнар кәттә булачак

Журналистлар белән әңгәмәгә Идел буе физик культура, спорт һәм туризм академиясенең өстәмә белем бирү үзәге җитәкчесе, авырлыгы артык булган балалар өчен «Үзгәрешләр җиле» исемле лагерь проекты авторы Татьяна Кириллова; балалар һәм үсмерләр ялын, мәшгульлеген һәм сәламәтләндерүне оештыру «Җәй» республика үзәге директоры Раил Муратов һәм Татарстан Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының социаль программалар һәм өстәмә белем бирү бүлегенең әйдәп баручы белгече Рөстәм Йосыпов килгән иде.

– Быел җәй республикада 218 меңләп бала төрле лагерьларда ял итәчәк. 13 мең вожатый кирәк булачак. Ярый әле аларның күбесе берничә смена рәттән эшләргә риза. Бу – 6-7 мең вожатый да җитә диган сүз, – диде Рөстәм Йосыпов.– Хәзерге заман баласының игътибарын чебурашка киемендә чыккан аниматор гына озак тотып тора алмый. Шуңа да замана әйдаманнарын (вожатыйларны) алдан ук әзерләргә кирәк. Лагерьлар төрле юнәлештә, төрле төрдә булганга күрә, әйдаманнар да төрле булырга тиеш.

– Быел беренче тапкыр безнең академия әйдаманнар әзерләү курслары башлап җибәрде. Ул башлыча студентлар өчен, – дип яңалыклары белән уртаклашты Татьяна Кириллова.– Курсларга йөрүче (яшьләре 18-64кә кадәр) 350 булачак әйдаман 76 сәгать эчендә шәфкать туташы, психолог, әти-әнисеннән аерым яшәүче баланың чын дусты һәм ярдәмчесе дә булырга өйрәнүләрен зачет биреп расладылар. Бирелгән сертификатлар өч елга ярый. Аларны академиябезнең профессор-мөгаллимнәре бушлай укытты. Казан студентлары белән бергә Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Әлмәт һәм башка район яшьләре дә белем алды.

Хәзер балалар арасында симерү кебек чир көннән-көн арткан бер заманда, Татьяна Кириллова алар өчен махсус лагерь оештырган. Менә өч ел инде бу лагерь уңышлы эшләп килә. Әлеге лагерьдан кайткач, балаларның 40 проценты спорт түгәрәкләренә йөри башлый.

«Җәй» директоры Раил Муратов балаларыбызның җәйге ялы өчен бик күпләрнең җаваплы булуын җиткерде.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Кечкенә принцессаларның зур гамәлләре

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Безнең фестиваль таҗлар, тасмалар, купшы күлмәкләр булуы белән генә матурлык конкурсларына охшаш. Ун ел дәвамында мин шушы сүзне сөйлим һәм бу фикерне тамырдан үзгәртер өчен ниндидер яңалыклар кертергә тырышам.

Әмма ун ел дәвамында безне «Мисс Татарстан» белән чагыштыралар, тик болар икесе ике төрле юнәлештәге проект, – дип белдерде «Татарстанның кечкенә Принцессалары» балалар җәмәгать оешмасы президенты Наталья Киселева журналистлар белән очрашу вакытында.

«Татарстанның кечкенә Принцессалары – 2017» республика фестивале старт алды. Әлеге вакытта гаризалар кабул ителә. Наталья Киселева аңлатуынча, сайлап алу турында теләсә нинди сәләте булган (җыр, бию, рәсем ясау, тегү, чигү h. б.) актив һәм үз-үзенә ышанган кызлар катнаша ала. Шулай ук балалар йортларында тәрбияләнүчеләргә һәм мөмкинлекләре чикләнгәннәргә дә фестивальдә катнашу мөмкинлеге тудырыла.

– «Татарстанның кечкенә Принцессалары» башка матурлык бәйгеләреннән принципиаль рәвештә аерылып тора. Без тышкы кыяфәткә карамыйбыз, ә бала турында тулаем фикер булдырабыз. Аны талант һәм яхшылык бәйгесе дип атасаң да була. Бәйге финалистлары алдына куелган төп бурыч – игелекле гамәлләр кылу. Фестивальдә алар хәйрия яки ниндидер социаль мөһим проектларны үзләре уйлап табып, шуны презентацияләп, тормышка ашырырга тиеш, – ди Наталья Киселева.

Фестивальдә җиңеп чыккан кызлар Татарстанны «Little miss World» халыкара конкурста тәкъдим итәчәк. «Татарстанның кечкенә Принцессасы – 2013» титулына ия булган Элина Зиновьева сүзләренчә, фестивальдә чыгыш ясаучы кызлар Татарстанда һәм Казанда уза торган һәртөрле хәйрия чараларында катнаша. Нәкъ менә шуңа күрә алар җиде яфракчык һәм җиде төстән гыйбарәт булган «Цветик-семицветик» дип аталган үзләренең проектларын булдырган. Ул бер ел эчендә сезонга икешәр зур чара үткәрүдән гыйбарәт. Җәй, көз, кыш һәм яз айларында төрледән-төрле, бер-берсенә охшамаган акцияләр, чаралар уздырыла. Шулай ук принцессалар «Альпари» хәйрия фонды үткәргән ярминкәләрдә дә актив катнаша.

✔ Татарстанның кечкенә Принцессалары – 2017» фестиваленең сайлап алу турлары 13-14 май көннәрендә «Горький парк» сәүдә үзәгендә сәгать 15.00 дә башлана. Финал өлеше 4 июньдә «Корстон»да булачак.

✔ Конкурста 5-15 яшьлек балалар һәм яшүсмерләр катнаша. Җиңүчеләр яшь буенча дүрт категориядә сайланып алыначак.

✔ Фестивальдә сигез кешегә төп таҗ кигертеләчәк. Аларның дүртесе – көмеш, дүртесе алтын белән йөгертелгән.

✔ Моңа кадәр кул эшләнмәләре ярминкәсеннән кергән акчалар мөмкинлекләре чикләнгән принцессаларга ярдәм итүгә тотылган булган. Башка еллардан аермалы буларак, быел фестивальнең финалына билетлар сатыла. Бәясе – ун сум. Әлеге һәм ярминкәдән кергән акчалар авыр тормыш шартларына эләккән бертуган сәләтле кызлар Камилә һәм Айгөл Нурдиноваларның дәвалауга тотылачак. Аларның гаиләсе күптән түгел генә юл һәлакәтенә юлыккан. Әтиләре вафат булган, әниләре авыр хәлдә хастаханәдә ята.

ДИН

Россия төбәкләре имамнары Казанга җыела

18-20 май көннәрендә узачак «Милли тормыш һәм дин» VIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумында илнең 68 төбәгеннән 1050 делегат катнашачак. Форум делегатлары дин өлкәсенә кагылышлы мөһим сораулар һәм мәсьәләләр буенча фикер алышачак. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ренат Закиров журналистлар белән булган матбугат очрашуында шулай дип белдерде.

Мондый чара беренче тапкыр 2005 елда уздырылган. Соңгы елларда исә ул тагын да масштаблырак – форум буларак үтә башлады. Анда катнашучыларның саны да елдан-ел артып тора.

– Моннан унбиш еллар элек дин әһелләре генә түгел, мөфтиләр дә бер-берсе белән аралашмый иде. Һәркайсы үз казанында гына кайнады. Без исә аларны бергә җыю традициясен булдырдык. Имамнар мондый чараларга үзләре дә бик теләп килә. Бу үзенең уңай нәтиҗәләрен дә бирә, – дип сөйләде ул журналистларга.

Форумга быел беренче тапкыр Еврей автоном өлкәсе, Амур, Брянск, Липецк өлкәләреннән, Хакассиядән дә имамнар киләчәк. Иң зур делегация, елдагыча, Башкортстаннан килер дип көтелә. Имамнар арасында яшьләрнең күп булуы да сөендерә. Катнашучыларның яртысын диярлек 1970 еллардан соң туганнар алып тора. Иң өлкән имамга исә 93 яшь. Ул – Хәким Биктиев, Калининград өлкәсеннән. Хәким ага шушы яшендә дә машина иярли. Бик актив кеше. Юлда йөрүне дә авырсынмый, чакырган җиргә бармый калырга ярамый, дип, форумга киләчәген белгерткән.

Форумның пленар утырышына кадәр делегатлар аерым секцияләргә бүленеп эшләячәк. Ислам дине һәм татар халкының милли үзенчәлеге; Болгар ислам академиясе – милли рухи фикерне торгызу үзәге; Мәчет һәм татар гаиләсе; ислам дине һәм күпкырлы матбугат секцияләрендә имамнарны борчыган күп мәсьәләләр турында фикер алышачаклар. Пленар утырышта исә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның да катнашуы көтелә. 20 май көнне делегатлар Изге Болгар җыенына барачак.

«Хәләл» туй фестивале узачак

Башкалада беренче тапкыр «Хәләл» туй фестивале үтәчәк. Проект авторы – Россия һәм Татарстан мөслимәләре берлеге рәисе Наилә Җиһаншина сүзләренчә, фестивальнең максаты – борынгы традицияләрне кайтару.

– Яшь кәләшләрнең үз куллары белән бирнә әзерләү традициясе югалды. Элек әбиләребез сөлгеләр чиккәннәр, кием-салым теккәннәр. Булачак иренә, аның әти-әнисенә бүләкләр әзерләгән. Шушы гореф-гадәтне яңадан кайтарасы иде. Яңа туган балага исем кушу йоласын да бәйрәмгә әверелдерсәк, ничек күңелле булыр иде. Ир баланы сөннәткә утыртуны да гади көндәлек чара итеп калдырасы килми. Болар барысы да ата-ананың күңелендә кала торган мизгелләр бит. Чара барышында менә шуларны күрсәтәсебез килә, – дип сөйләде ул «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында.

«Җәннәт» үзәген оештыручыларның берсе булган Елена Грачева фестивальгә аш-су, кул осталары, тамадалар, дизайнерлар, фотографлар һәм видеооператорларның да чакырылуын хәбәр итте.

– Без аларга никах, мөселман туйларын ничек матур һәм күңелле итеп оештырып булуын күрсәтәсебез килә. Чарага тиздән кияүгә чыгарга, өйләнергә җыенган яшьләрне дә чакырабыз. Алар аннан үзләре өчен, һичшиксез, яңалыклар алачак, – ди ул.

«Туган авылым» милли комплексында узачак фестиваль кысаларында хәләл туй индустрия күргәзмәсе дә оештырыла. Россиядән генә түгел, Иране килүче дизайнерлар никах күлмәкләре тупланмасын тәкъдим итәчәк. Кул эшләре осталары Арча һәм Әлмәттән киләчәк. Алар кызларга бирнә әзерләү серләрен дә өйрәтәчәк.

Наилә Җиһаншина журналистларга Казан абыстайлары институтын яңарту идеясе барлыгын да сөйләп үтте.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Үзебезчә яшәп, үзебезчә озатыйк

Мәетне соңгы юлга озату – исән калганнар өчен шактый дәрәҗәдә мәшәкатьле һәм җаваплы эш. Һәр мөселман әһеле госелләндерелеп, кәфенләнеп, җеназа намазы укылып озатылырга тиеш. Моны һәркем белә кебек. Тик ошбу гамәл кайчакларда җиренә җиткерелеп үтәлми.

Әйтик, фаҗигале төстә вафат булган яки сырхавына карап кисәк кенә үлгәннәрне иң элек моргка алып барып яралар, сәбәбен тикшерәләр. Туганнары үтенече буенча, шунда ук шланг белән юалар. Ләкин бу һич тә госел коендыру түгел, ислам дине кануннарына туры килми. Мәетне өйдә юучылар да бар. Анысы әйбәт, әмма йорт хуҗалары моңа әзерме соң? Алар, аһ-уһ килеп, комган, колаша (мәет юа торган тагарак), җаймәләре белән җеназа корылмасы (анысында махсус «дугалар» да бар), кәфенлек, ләхет такталары эзләп чаба. Ә мәрхүмнәрне көне-сәгатендә җирләргә кирәк. Динебез шулай куша. Башка төшкән кайгы-хәсрәт өстенә никадәр мәшәкать өстәлә. Шуларны искә алганда, мәчетләребез каршында җеназаханәләр кору зарури бер гамәл булып тора. Намаздан соң анда катнашкан бөтен кеше ишегалдына чыгып җеназа намазын укый. Ул никадәр күп кеше белән укылса, савабы шулчаклы мулдан языла. Соңгы елларда бу нәрсәгә зур игътибар бирелә. Шәһәребезнең кайбер мәчетләре каршында җеназаханәләр эшли башлады. Гаять файдалы, күркәм гамәл. Мисал итеп «Казан нуры» мәчетен китерәсем килә. Заманында аны торгызуга үз өлешемне кертә алуым белән горурланам. Йәмән җөмһүрияте иганәчеләре химаясенә, ун ел дәвамында, гарәп аркадашларым белән арадашчылык итеп, Казанда, район-авылларда мәчет-мәдрәсәләр җиткердек. Сүзем «Казан нуры» мәчете турында иде. Аны муллалар нәселеннән килгән Габдулла улы Шамил хәзрәт Исхакыйдан башларга кирәктер. Шәҗәрәләре Сөембикә-ханбикәнең башбирмәс нойоны (тарихта мәгълүм шәхес), хәрби түрә Меки Янчурага (14…–1558) барып тоташа. Ошбу зат Казан ханлыгы Явыз Иван тарафыннан җимерелгәч тә кулыннан коралын ташламый – элеккеге Чаллы ханлыгы биләмәләренә күчеп (кирмәне Балык Бистәсе районы, Мәбәрде Чаллысы янындагы биеклектә була), канлы көрәшне дәвам итә. Үзеннән соңгыларга әйбәт үрнәк калдыра.

Генералның уҗәтлеге хәзрәтебез Шамил абыйга да килеп җиткәндер дип уйлыйм бүген. Аксакал Казансу буенда күркәм бер мәчет торгызу хакында хыялланды. Таш-кирпечтән түгел, чәере аңкып торган нарат бүрәнәләрдән булсын дия иде. Һәм ул теләгенә иреште – Мари Иле урманнарыннан агач ташып, Халыкара ЮНЕСКО фондына теркәлерлек (бусы киләчәк эше) «Казан нуры» мәчетен торгызды. Янәшәсенә шундый ук күркәм мәдрәсә салып куйды. Вафатыннан соң хаклы рәвештә «Шамил мәдрәсәсе» дигән исем бирелде. Хәзер анда олысы-кечесе дини белем ала.

Шамил абыйны борчыган бер мәсьәлә чишелмичә калган иде. Нияте – мәчет янында «Җеназаханә» кору. Имамыбыз: «Мәетне моргта шланг белән юуны туктатырга кирәк, бу гамәл динебезгә каршы килә», – дип, шактый еллар Татарстан Диния нәзарәте бусагасын таптады. Аксакалның уй-теләкләрен улы, «Казан нуры» мәчете мөтәвәллияте рәисе, Татарстан Президентының ярдәмчесе Камил Исхаков тормышка ашырды. Камил Шамил улы тырышлыгы белән, мәчетебез янәшәсендә менә дигән җеназаханә төзелде. Хәзер инде якын-тирәдәге бистә кешеләре вафат булган якыннарын, бөтен уңайлыклары җитешле бинада дин әһелләре тарафыннан хезмәт күрсәтелеп, киң җәмәгатьчелек катнашында җеназа намазын укытып, соңгы юлга озата ала. Бик тә уңайлы һәм саваплы эш. Борчылып, кайгырып, анда-монда чабасы түгел.

«Казан нуры» мәчетенең ишекләре һәркем өчен ачык. Кереп намаз укыгыз. Авыр чакта чишә алмаслык булып тоелган мәшәкатьләрегезне имам-хәзрәтләребез белән бергәләп хәл кылырбыз, иншаллаһ.

Госман ГОМӘР, «Казан нуры» мәчете мөтәвәллияте әгъзасы.

ЭКГ ишеге төбендә

Бүлмәсенә керүгә: «Ишек төбендә кызларны сез күлдерәсезме анда?» – дип күлемсерәп кенә сорап куйды Лилия Салихова.

Балтач хастаханәсенең йөрәк яздыру эшенә нәкъ аны куюлары әйбәт булган. Лилия сеңелнең сөйләшүе дә, карашы да кешеләрне тынычландыра торган. Мондый фикергә бүген генә килүем түгел инде. Соңгы өч елда бу бүлмәгә шактый еш керергә туры килде бит.

– Әйе, бүген анда барысы да шат күңелләләр җыелган иде бугай, күләргә генә торалар, – дип җавап бирдем мин, табибның соравына каршы.

Дәшмәде. Шат күңелле кешенең дә каты авыру булуы мөмкин бит әле дип уйлап куйгандыр, бәлки.

Бүген иртән мин бу ишек төбенә килеп басканда, ике-өч кеше бар иде инде. Чират буенча кем ахырдан икәнен сорадым. Араларыннан берсе бик сүзчән икән, үзләреннән соң тагын кемнәр барлыгын санады да мине сигезенчегә чыгарды. Ярый бу, Ходай кушса, озак көтәргә туры килмәс, мөгаен. Ә менә гомуми анализга кан бирү өчен озаграк көтәргә туры килмәгәе, чөнки анда, гадәттәгечә, кеше шактый күп күренә. Минем кебек диспансеризация үтүчеләр чиратсыз керә ала диелә диелүен. Авылыбыз фельдшеры Фәридә ханым да шулай дигән иде, әмма алай түгелләген шулай дип әйтүчеләр дә, каралырга килүчеләр дә белеп тора. Монда кем диспансеризация үтәргә, кем хезмәт урыны буенча акча түләп (һәм чиратсыз) медицина тикшерүе узарга, кем инвалидлык юлларга, кем авырып килгәнен аерып кара син! Авыручылар чиратына керергә тырышу үзе үк кешелексезлек булыр иде. Шуңа күрә биредә чынлап та чиратсыз керүчеләр – кечкенә балалар гына.

Анализга кан алдыру бүлмәсе дә янәшәдә генә диярлек, анда барып та чират алып куйдым. Күпләр шулай итә, ике генә түгел, әллә ничә бүлмәгә чират ала да, анннары ишек төпләре арасында тызбыз йөри. Кем мондый мәшәкатькә юмор беләнрәк карый, кем сукранып йөри – кешенең холкына карап инде. Булдыра алсаң, моңа уен-көлке белән каравың отышлырак. Бер бүлмәдә табибка каралган арада, икенчесенә чиратың үтеп китсә генә читенрәк. Ярый ла синнән соң чиратка басканнар, хәләңә кереп, сине «танысалар»! Киресенчә дә булгалый шул. ЭКГ ишеге янында да бер ир-ат: «Китмәскә иде ишек төбеннән, «койрыкка» барып басыгыз да, иң ахырдан керерсез», – дип, ике хатын-кызны пыр туздырып ташлады. Ул ханымнар авылдан килгән сатучылар иде бугай, сөйләшүләреннән шулай аңлашылды. Сатучыны сүз белән кем җиңгән ди әле, үз вакытларында йөрәкләрен яздырып чыктылар барыбер. Тар күңеллелек юк икән үзләрендә, чиратым алардан соң булса да, миңа үзләреннән алда керергә тәкъдим иттеләр. Ризаламмы соң, мине тәмам бабайсытулары бит боларның. Бер ашыгыч эшем дә юк. «Бигрәк тыйнак бабай булдың әле син!» – дип тә чәпеделәр җитмәсә. Теге ир-ат әллә ничә табибка чират тору тәртипләрен белеп бетерми, күрәсең. Бирегә беренче генә килүедер инде. Килмәгән-авырмагансың икән, шул бәхетеңә шатланасы гына бит югыйсә, ә ул дөмерелеп утыра.

Күрше ишек төбен урап килим әле дип кенә барган идем, хәзер чиратың җитә, ерак йөрмә, дип туктатты бер ханым. Ишек төпләрендәге һәр төркемдә диярлек чиратны тәртипләп, белмәгәннәргә аңлатып торучы бер ханым була ул, рәхмәт төшкере. ЭКГ ишеге янында да бар иде андый. Табибка өченче булып керәсе иде ул. Беренче кергән кеше озаграк торгач, аның ник озакланганын юрый башладык та, йөрәге ике булып чыккандыр, шунлыктан ике йөрәк яздырган кадәр вакыт үткәндер, дигән нәтиҗәгә килдек. Бер көлешеп алыр өчен шушы сүз җитмәгәнмени?

Ишек төбенә яңалар килә тора, «Кем ахырдан?» дип сорый тора. Җавапны, билгеле, теге Сүзчән ханым бирә:

– Менә бу бабайдан соң бер апа чират алып китте, аннары син буласың.

Ничә кеше килсә дә, аның җавабы бер үк сүзләрдән башлана: «Менә бу бабайдан соң...» Бу бабай да бу бабай дип үзәккә үткәч, бүлмәгә чиратсыз куып кертерлек булдым аны. Менә кереп китте һәм... шактый озак торып чыкты.

– Синдә дә ике йөрәк тапты, ахры, – дип көлешеп алдык.

– Минем эш бетмәде әле, чыгып монда утырып торырга кушты, – диде ханым.

Ул арада йөрәк яздыручы да, бүлмәсеннән чыгып, каядыр китеп барды, кулында ниндидер кәгазь иде. Бераздан бер шәфкать туташы килеп, Сүзчәнгә ниндидер таблетка каптырды. Әле генә каты шаулашмаска тырышып тыйнак кына көлешкән төркемебез бөтенләй тынып калды. Йөрәк яздыручыбыз бүлмәсенә кайтып нәрсәнедер хәл иткәч, Сүзчәнебез дә юкка чыкты. Ятып дәваланырга салдылар, диде кемдер. Табибның кулындагы кәгазь – аның йөрәк язуы булган, ахрысы. Язуны зуррак белгечкә, бәлки хастаханәнең зур тәҗрибәле терапия бүлеге мөдире Рүзәл Камалиевка күрсәткәндер дә авыруны кичекмәстән стационарга салырга булганнардыр. Ходай сәламәтләнергә язсын аңа! Без диспансеризациягә дә, бүтән кайбер тикшерүләргә дә бер «галочка» чарасы диебрәк карыйбыз каравын да, алай гына түгел икән менә. Ачыкланган авыруны тиз арада дәваларга керешү очраклары да бар икән! Ярый бит. Һәркемнең гомере бер генә, шулай саклый күрсеннәр аны.

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ.
Балтач районы,
Карадуган авылы.

ПОЧТАДАН

Бүген телевизорны ачсаң, гадәттән тыш хәлләр, катастрофалар, су басулар, янгыннар турында сөйлиләр. Эфир ток-шоу, сериаллар белән тулган.

Ярат дип кенә яраттырып булмый

Совет чорында яшьләрнең үзаңында Ватанны саклаучы образы Шакирҗан Мөхәммәтҗанов (Александр Матросов), Зоя Космодемьянская, герой-пионерлар мисалында нык формалашкан иде. Ә бүген боларның эзе дә юк. Укучыларның 70 проценты Бөек Ватан сугышы геройларының исемен әйтә алмый.

Татарстан мәктәпләрендә 8-11нче сыйныф укучылары арасында сораштыру уздырганнар. «Нинди кыйммәтләрне өстен күрәсез?» дигән сорауга укучыларның 32 проценты – «акча», 28 проценты – «машина», 22 проценты күңел ачу дип җавап бирсә, бары 18 проценты гына «Ватан» төшенчәсенә өстенлек биргән.

Ватанпәрвәрлек, патриотизм – Ватаныңны ярату, үз халкың белән горурлану, аны якларга әзер булуны аңлата торган әлеге төшенчәләрне бүгенге яшьләр аңламыймы соң әллә? Балаларга әти-әниеңне, Ватаныңны ярат, дип кенә яраттырып булмый. Ватанпәрвәрлек һәркемнең йөрәгендә булсын, тәрбиядән сеңсен иде. Үзебез яшәгән Татарстанны яратудан, аның тарихын, телен, гореф-гадәтләрен хөрмәт итүдән башларга кирәк.

Нияз БИШБАЛТА,
Казан.

ҮРНӘК

Борис Кириллович Кузнецов исемендәге кадетлар мәктәп-интернатында 360 бала белем ала. Шуларның 120се интернатта яши. Күбесе Казан янындагы районнардан килгән. Кадетлар уку белән генә түгел, спортта да алдыра. Нинди генә ярышларда җиңмәгәннәр! Яулаган кубоклары, мактау грамоталарының исәбе-саны юк.

Мәктәпнең десантчылар клубы үзе бер. Аны офицер-тәрбияче Тәлгать Камалиев җитәкли. Егетләр белән эшләгәндә төп принцип – үрнәк күрсәтү дип саный ул. Үзе дә һава десанты гаскәрендә хезмәт иткән, үзенчәлекле хәрби хезмәт юлы узган. Ә инде янәшәңдә шундый кеше булганда, ничек десантчы булырга хыялланмыйсың инде. Моның өчен беренче чиратта таза-сәламәт булуың шарт, билгеле. Димәк ки, спортның берничә төре белән шөгыльләнү таләп ителә дигән сүз. Шулар арасында иң мәртәбәлесе – парашют спорты. Монысына да өйрәтә Тәлгать Камалиев. Биредә 14 яшьтән парашют белән сикерә башларга рәсми рөхсәт алынган. Офицер монда да үрнәк. Инде 56 яшькә җитүенә карамастан, яшь парашютчылар белән һәрвакыт янәшә ул. Кем әйтмешли, җирдә дә, күктә дә. Бигрәк тә беренче тапкыр парлап сикерергә үтенәләр икән кадетлар.

– Җиргә төшкәч, аның күзләре ничек очкынланып януын күрсәгез икән! Икенче тапкыр аны тотып тыеп булмый инде... – дип сөйли Тәлгать Камалиев егетләр турында.

Бүгенге көндә парашют белән сикерүчеләр арасында алдынгылыкны Михаил Жуков исемле егет тота икән, 67гә җиткән аның рекорды. Бу арада округ ярышларында катнашырга киткән егетне зур түземсезлек белән көтте иптәшләре. Аннан инде ул үз исәбен 80гә тутырып кайтачак.

Ильяс САЛИХҖАН.

Җәмәгать, мин – исән!

Сәламәтлек

Яз җитүе миңа сөенче кебек тәэсир итте. Быел иртәрәк тә абайладым аның башлануын. Кала урамнарында йөргәндә таш йортлар күләгәсеннән якты якка чыкканда ук сизелде аерма. Сәламәт кеше моңа куанмыймы инде! Менә шул шул: сәламәт булсаң гына ямьле дөнья. Әйе, байтак кына вакыт интектереп теңкәгә тигән зәхмәтне җиңеп аякка басуыма сөенеп туя алмыйм. Яңадан туу белән бер дисәм дә ярый моны.

Әлбәттә, шатлыгым белән уртаклашасым килә. Нинди зольмәттән чыгуымны белгертү өчен, Казан онкология үзәгендә дәвалануымны әйтүем дә җитәр кебек. Тәгәлрәге, Республика клиника онкология диспансерының ашказаны юлы (үңәч) хирургиясе бүлегендә операция ясатырга туры килде. Анда эшләүче табибларга рәхмәт. Сихәтләнүем – тулысынча аларның тырышлыгы. Мин хастаханәгә дүшәмбе көнне кердем һәм шул ук атнаның җомгасында, скальпель кискән җөйләргә соңгы тапкыр перевязка ясатып, өйгә кайтып киттем. Марля тампоннарын куйганда шәфкать туташының: «Бу – ювелир эше!» – дип, хирургны мактавы истә калды.

«Ювелир» дигәнебез – операция ясаучы хирург, медицина фәннәре докторы профессор Михаил Бурмистров. Һәр авыру операция ясаучының алтын куллы оста булуын тели, билгеле. Тикшерүләр узып йөргәндә үк мин Бурмистровның югары профессионал булуын ишеттем. Ә инде очрашып сөйләшкәч, соңгы шикшөбһәләрем дә таралып юк булды. Мөлаем карашлы бу кешенең ирләрчә көчле итеп кул кысып күрешүе, шул ук вакытта үзен гаҗәп тә тыныч тотуы – сүзе эшеннән аерылмый торган инсан икәнлегенә инандырды.

Инде менә терелеп аякка баскач тагын очраштык, бу юлы интервью алыр өчен эзләп таптым мин аны. Михаил Владимирович белән әңгәмәмне хастаханәдә ишеткән бер хәлне искә төшерүдән башладым. Һаман онытылмый, күңелемне тырнап тора шунда сөйләнгән хәл һәм, дөресен генә әйткәндә, кулыма каләм алырга этәргеч биргән хикмәт тә шул иде.

Палатада ятканда, бер иптәш: «Сезне ничектер, мине оныттылар бу дөньяда. Онкология үзәгенә баруымны белүгә, таныш-белеш кенә түгел, дуслар һәм хәтта кайбер туганнар да араны өзде. Хәлне белешер урында, хәзер сөйләшмиләр дә. Телефоннан шалтыратмыйлар, миңа җавап та бирмиләр...» – дип уфтанып алган иде.

Бу сүзләр ул чакта артык уйландырмады. Һәркемнең үз хәле хәл дип карарга күнегәсең сырхауханәдә. Бәлки шуңадыр. Ни гаҗәп, андый моң-зарны тагын ишетергә туры килде миңа. Операция ясатып өч айдан соң тикшерүләр узган чагында очраган авырулар арасында да күтәрелде ул сүз. Нәкъ тегенекенә охшаш хәл. Әнә берсенең кайбер танышлары, аның килүен күргәч, урамның икенче ягына ук чыгып китәләр икән...

Ни соң бу? Авырган кешегә ярдәм итәр урында аннан йөз чөерүне аңлап та, аңлатып та булмый. Бәлки, диагноз куркыта торгандыр...

– Бу – бары тик наданлык! Онкология чире йогышлы авыру түгел, куркырга кирәкми аннан. Ә менә әхлак ягын уйлап карау зыян итмәс, – ди ул.

Әлбәттә, белгеч хаклы: бу йә аңлап бетермәү, йә рухи гариплек.

– Михаил Владимирович, менә нәрсәне әйтсәгез иде: узган ел Республика Онкологиягә каршы көрәш елы дип игълан ителгән иде, шуның белән бәйле рәвештә, халыкны агарту эше алып барылдымы? Гомумән, ул чара нинди нәтиҗәләр бирде?

– Халыкның медицина буенча белемен күтәрү эшен алып бару һәрвакыт зарур. Әлеге чара кысасында, халыкны күпләп тикшерү уздырылды. Нәтиҗәсе уңышлы килеп чыкты: аннан алдагы ел белән чагыштырганда, үлем-китемне сизелерлек киметүгә ирештек. Ә бит онкология белән авыручылар саны арта бара... Чир никадәр иртәрәк ачыкланса, аны дәвалау шулкадәр өметлерәк.

– Никадәр гомерне газраил кулыннан йолып алуыгыз һичшиксез куандыра. Тик менә бу зәхмәтнең барыбер тарала баруы сагайта. Безнең заманда тормыш шартлары яхшыра да кебек инде, ә ул каһәр төшкән чирнең арта баруы ни сәбәптән икән соң?

– Беренче сәбәп – кешенең дөрес тукланмавында, ризыкның сыйфатсызлыгында. Аннан соң – экологиянең начарлануы, анысы икенче урынга чыкты хәзер.

– Сез әйткәннәргә чик куя алабыз ич без. Хуп. Ә инде чир аяктан екса, аны дәваларга – мисалга, минем очракта операция ясатырга Казанда ныклы нигез булуына үзем шаһит. Үзем яткан бүлектә кешене операциягә әзерләү, ясау һәм, ниһаять, операциядән соң аны карау бик яхшы алып барылуын күреп, күңелем булды. Катлаулы булуына карамастан, эш яхшы оештырылган.

– Бу, әлбәттә, профессор Евгений Сигал җитәкләгән коллективыбыз – табиблар һәм шәфкать туташлары тырышлыгы нәтиҗәсе. Биредә өлкән шәфкать туташы Кадрия Гафиатуллинаның фидакарьлеген дә аерым искә аласым килә.

– Без, авырып ятканнар, аларның барысына рәхмәтле. Хастаханәдәге эшнең бөтен нечкәлекләрен белеп бетермәсәк тә, төп эшне хирург башкаруын аңлыйбыз. Бу һөнәр иясенә табигый сәләт бирелергә тиештер, минемчә. Һәм шул ук вакытта хирург та айдан төшми... Озын сүзнең кыскасы, Михаил Владимирович, үзегезнең ни өчен бу һөнәрне сайлавыгызга килсәк...

– Чыннан да, кеше очраклы гына хирург була алмый. Тәҗрибәмнән чыгып әйтәм.Мин үзем мәктәптә укыганда ук хирург булам дип уйлый идем. Нәкъ шул хыялымны тормышка ашырырга теләп, сигезенче сыйныфтан соң мин медицина көллиятенә укырга кердем. Һәм бер үк вакытта биредә медбрат булып эшкә керештем. 1988 елдан бирле эшлим монда, ул чакта әле ул 15нче шәһәр хастаханәсе дип атала иде. Аннары Казан дәүләт медицина институтында укыдым. Студент чагымда «Ашыгыч ярдәм» хезмәтендә волонтер булып та эшләдем. Кеше тормышында хирургның хәлиткеч роль уйнавын шунда күрдем. Күрдем дип, еш кына ашыгыч операцияләрне башкарырга да туры килә иде. Җыеп кына әйткәндә, диплом алу белән бергә, мин скальпель тотып эшләү тәҗрибәсен дә туплый башладым. Әйткәнемчә, 1988 елдан бирле шушында хезмәт куям.

– Киләсе елга 30 ел тула икән. Сез инде хәзер тәҗрибәле хирург булу белән бергә фән өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкәнсез – медицина фәннәре докторы, профессор. Шулай да, яшьрәк чагыгызны искә төшереп, үзегезнең остазыгыз кем булуын әйтә аласызмы?

– Ерак йөрисе юк: хастаханәдәге бүлек башлыгы профессор Евгений Иосифович Сигал – минем җитәкчем. Аның җитәкчелегендә күтәрелдем фән дигән «тау» буйлап. Евгений Иосифович – күренекле шәхес! Безнең тармакта операция ясауның яңа алымын – лапароскопияне иң беренче булып ул кертте. Гади генә итеп әйткәндә, ярып ташламыйча кечкенә генә тишекләр ясап операция үткәрү ул. Авыру кеше, әлбәттә, аны күпкә җиңелрәк кичерә, кечкенә җөйләр тизрәк төзәлә...

– Хәзер үзегез яшьләрне өйрәтәсезме соң?

– Әлбәттә. Минем кул астымда җиде егет медицина фәннәре кандидаты диссертациясен яклады. Докторлык диссертациясен яклаучылар да бар. Белем эстәргә, тәҗрибә арттырырга бөтен Россиядән һәм хәтта БДБ илләреннән дә белгечләр килә безгә. Киләсе атнада БДБ илләреннән курсантлар җыелачак. Аларга лекция укыячакмын, мастер-класс күрсәтәчәкмен...

– Табиблар һәрвакыт җитди. Хастаханәдә башкача мөмкин дә түгелдер. Ә менә профессор Бурмистровның ничек ял итүен белеп булырмы икән?

– Ялга вакыт каламы дип сорагыз сез! Әле бит безнең командировкалар да бар. Фәнни конференцияләрдә, симпозиумнарда катнашырга һәм анда чыгыш ясарга туры килә. Димәк, алдан әзерләнергә дә кирәк... Ял итәргә вакыт бик аз кала. Шулай да, эшләрдән бушаган арада, мин китап укырга яратам. Нинди әсәрләр дигәндә, җитди документалистикага өстенлек бирәм. Күбрәк тарих темасына язылганнар белән кызыксынам һәм узган гасырдагы Ватан сугышы турындагы документаль китапларга да күңелем төшә. Соңгысы, бәлки, бабамның йогынтысыдыр: ул – фронтовик, танк йөрткән. Анатолий Максимович Мәскәү янында сугышка кереп, Берлинга хәтле барып җиткән...

Әңгәмәдәш – **Ильяс САЛИХҖАН.**

Михаил Бурмистровтан киңәшләр

Кеше үзендә онкология авыруы барлыгын белде ди. Аңа нишләргә?

Беренче чиратта, каушамаска, курыкмаска. Бу әле дөнья бетте дигән сүз түгел! Төшенкелеккә бирелмәскә, үз-үзеңә, тереләм, дип максат куярга һәм дәвалаучы табиб белән союздаш булырга кирәк. Онкология хастасының 1нче һәм 2нче стадиядәгеләре дәвалауга бирешә һәм җиңелә. Шуңа күрә, үзеңне сау хис итсәң дә, тикшерелергә оялма. Никадәр алданрак беленсә, шулкадәр тизрәк бетерелә ул зәхмәт. Гомумән, ирләргә – 45 яшьтән, ә хатын-кызларга тагын да иртәрәк тикшерелергә киңәш итәр идем.

МӘДӘНИЯТ

Наил Дунаевка – орден белән машина ачкычы

Шушы көннәрдә Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты профессоры Наил Дунаев үзенең 80 яшьлек юбилеен бәйрәм итте. Бу уңайдан Президент Рөстәм Миңнеханов юбилярны «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләде.

Камал исемендәге театрда 55 елдан артык гомерен сәхнәгә багышлаган артист һәм педагогны дәүләт җитәкчеләре исеменнән Татарстанның Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова котлады.

– Тукай ролен сәхнәгә менгерүчеләр аз булмады, ләкин сез уйнаган Тукай йөрәкләрдә уелып калды. Бәхтияр, Хөсәен Ямашев кебек тарихи шәхесләрне уйнадыгыз. «Гөргөри кияүләре»ндәге ролегез дә бик шәп булып чыкты. Керәшеннәрнең яшәү рәвешен, аларның гореф-гадәтләрен күрсәттегез. Сез – киңкырлы артист. Рус һәм чит ил авторларының пьесаларын да тәрҗемә иттегез, – диде Римма Атлас кызы һәм Наил Дунаевка Президент бүләге булган «Форд» автомобиле ачкычларын тапшырды. Шулай ук Минтимер Шәймиевнең котлавын ирештерде.

«Крәшен сүзе» газетасы мөхәррире Людмила Белоусова, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты проректоры Роза Әхмәдиева, туган ягы Зәй һәм Мамадыш районнары җитәкчеләре, татар театрлары директорлары, режиссерлары тәбрикләде. Минзәлә театрыннан Татарстанның халык артисты Рәзилә Муллинаның: «Сезнең уйнаганны күреп җан сөенә. Сәхнәдә бик җиңел уйныйсыз. Сез бүген дә бетен хатын-кызларны гашыйк итәрлек ир заты», – дигән сүзләрен Наил Дунаев кичәдә тагын бер кат исбатлады. Ул үзе уйнаган кайбер спектакльләрдән өзекләрне тамашачының да хәтерендә яңартты. Укытучыларын котларга бүгенге көндә танылган шәхесләр булып өлгергән, төрле театрларда эшләүче укучылары да килгән иде. Түбән Кама театры режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Галиев студент елларын искә алды.

– Шушы мәртәбәле урында басып торырлык шәкерт итеп тәрбияләгәннәр икән, без укытучыларыбызга рәхмәтле. Гомер буе Сезнең йөзегезгә кызыллык китермәскә тырышабыз, – диде ул.

Башкортстанның халык артисты Илдар Гомәров исә юбилярга үзе иҗат иткән әр-яңа җырын бүләк итте. Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев, Татарстанның атказанган артисты Олег Фазылҗанов, Алинә Кәримова, Ришат Әхмәдуллин, Раил Шәмсуаров һ.б. юбилярны җыр аша тәбрикләделәр.

Щепкинчылар исеменнән халык язучысы Рабит Батулла котлады. Үзләренең мәктәп елларындагы истәлекләре белән дә уртаклашты. Театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев артистка рәхмәтен ирештерде.

– Театрда Наил Дунаев дигән артистның булуы – зур бәхет. Аның кыяфәте Голливуд көнләшерлек. Сәхнәдә эшләгәндә аның кебек нечкә күңелле артист юк. Ул – сәхнәдә күз яше белән елый торган бердәнбер ир-егет. Вакыйгаларны шундый ихлас кичерә, – диде ул.

Наил Дунаев республика һәм театр җитәкчеләренә рәхмәтен җиткерде.

Күренекле композитор Сара Садыйкова җырларыннан торган «Бибисара моңнары» дигән китап Зур концертлар залында тәкъдим ителде.

«Бибисара моңнары» дөнья күрде

Кичәне композиторның кызы Әлфия Айдарская оештырды һәм алып барды. Тамашачыга ул әлеге җыентыкның эшмәкәр Илнар Җамалиев тырышлыгы белән дөнья күрүен җиткерде. Илнар әфәнде – сәнгатьне яратучы, рухи яктан да бай булган ир-егетләрнең берсе.

– Сара апа Садыйкова – татар халкының зур байлыгы ул. Әлфия ханым үзенең ярты гомерен Сара апа иҗатын барлауга багышлады, – диде ул.

Мәскәүдән килгән «Шатлык» ансамбле җитәкчесе Зәмзәмия Сәхабетдинова Әлфия Айдарскаяга Татарстанның Мәскәүдәге илчесе, Премьер-министр урынбасары Равил Әхмәтшин исеменнән «Җәлилнең 110 еллыгына багышланган истәлек медале»н тапшырды.

Китапка кергән җырларны Татарстанның халык артистлары Зөһрә Сәхабиева, Георгий Ибушев, шулай ук Айдар Габдинов, Фәнис Мохтаров кебек урта һәм яшь буын җырчылар башкарды. Җырларның кайберләре әлеге кичәдә беренче мәртәбә яңгырады. Кичәгә Актаныш районы вәкилләре дә килүе очраклы түгел. Заманында Сара апа Сөн буйларына кайтып, җырлар иҗат иткән һәм ялларын үткәргә яраткан. Кичәдә җырларның авторлары – шагыйрьләр дә чакырулы иде. Әлфия Айдарская сәхнәгә күтәрелгән һәркемгә җыентыкларны бүләк итте.

– Әни үзенең бәхетле чорын язучылар, шагыйрьләр арасында үткәрде, гомеренең соңгы көннәренә кадәр алар белән иҗади дуслыкта яшәде, – диде Әлфия ханым.

«Үземне тискәре рольдә сыныйсым килә»

ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ

Артур Шәйдуллинның зур сәхнәгә тәүге адымнары «Банкрот» спектаклендәге Закир роленнән башланды. Сөйкемлелеге өчен яратып калды аны тамашачы. Бүген укучыларыбызны аның белән якыннанрак таныштырырбыз.

– Артур, син шәһәрдә туып-үскән егет. Ничек уйлыйсың, туган телгә мәхәббәтне гаиләң тәрбияләдеме, әллә мәктәпме?

– Минемчә, ана теленә нигез гаиләдә салына. Без өйдә һәрвакыт татарча сөйләштек. Сәнгатькә мәхәббәтне 16нчы гимназиядә Роза апа Ибәтова уятты. Беренче сыйныфта ук мине театр түгәрәгенә алганы өчен аңа рәхмәтлемен. Тел байлыгын үстерүгә этәргеч булды ул. Камал театрында булган премьераларны карап үстем. Укуны тәмамлаганда, үзем дә театр турында хыяллана башладым. Кайбер укытучылар: «Акчалы эш түгел бит, башка һөнәр сайлыйсыңмы әллә?» – дип тә үгетләп карадылар. Әмма хыял өстен булып чыкты. Театр училищесына укырга керү белән бөтенләй икенче дөньяда яши башлаган кебек булдым. Анда Фәрит Бикчәнтәев кулына, соңрак Камал театрына эләгү зур бәхет булды.

– Урта буын артистлардан аеруча кемнең уйнавын ошатасың?

– Әле дә хәтеремдә, 11нче сыйныфта «Тәкъдир» спектаклен карадым. Баш рольдә Искәндәр Хәйруллинны күреп бик сокланган идем. Ә инде өлкән артистлар белән гомумән горурланабыз. Аларга карап, сәхнә осталыгына өйрәнәсең.

– Спектакльләрдә уйнаудан тыш, үзеңне тагын кайсы өлкәләрдә сынап караганың бар?

– Мин укыганда ук биюгә омтылдым, бию белән шөгыльләнәм. Узган ел Салават Юзеев төшергән «Киллер» дигән кыска метражлы фильмда төштем.

– Ничек уйлыйсың, артист күбрәк театрда ачыламы, әллә кинодамы?

– Минемчә, театрда. Анда көч күбрәк китә. Театрда ачыласың, кинода күренәсең. Театр артистына кинода төшү авыррак, минемчә. Анда яшәргә кирәк.

– Артист театрда да яшәргә тиеш, дигән гыйбарә бар...

– Алай гына түгел, уйный торган спектакльләр дә бар. Мәсәлән, «Гөргөри кияүләре», «Хуҗа Насретдин» кебекләрдә уйнарга кирәк.

– Артист халкы бик игътибарлы. Урамда булсынмы, транспорттамы, ул кешеләрнең йөрешләрен, сөйләшү рәвешләрен күзәтергә ярата, холыкларын өйрәнә.

– Әйе, артист күзәтүчән булырга тиеш. Кызыклы кешеләрне күрсәң, алар онытылмый. Кайчан да булса, әгәр үз ролеңә туры килсә, аларның сөйләшүен, гадәтләрен сәхнәдә күрсәтәсең.

– Тәнкыйтьләгәннәре бармы әле үзеңне?

– Әлбәттә, бар. Ул хаталарыңны башка күзлектән карап әйтсәләр, артистка ниндидер стимул бирә.

– Коллективта яшьләр арасында көнләшүчеләр дә булмый калмыйдыр...

– Үзем көнләшмәгәч, башкаларны да көнләшә дип уйламыйм. Бер-береңнең уңышларына шатланырга гына кирәк. Көнләшү бик начар гадәт.

– Моңа кадәр син алдыңа куйган максатларыңа ирешә килгәнсең. Үзең теләгән уку йортын тәмамлап, яраткан һөнәреңне сайлагансың. Бүгенге көндә нинди максат белән яшисең?

– Хәзерге вакытта иң зур максатым – гаилә кору.

– Тормышта үзеңә таяныч булырдай кешене таптыңмы әле?

– Мин мәдәният һәм сәнгать институтында укый башлагач, эстрада факультетында укучы кыз белән таныштым. Ул бүгенге көндә эстрадада эшли. Икең дә сәнгать кешесе булганда, гаиләдә җиңелрәк дип уйлыйм.

Сәхифәне Люция ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде.

Телне тырышып өйрәнгән өчен – 500 мең

Совет районының 162нче балалар бакчасы 2017 елда, «Иң яхшы билингваль бакча» бәйгесендә җиңеп, 500 мең сумлык сертификат белән бүләкләнде. Балаларга ике телдә тәрбия бирүдә яңа алымнар кулланып, тагын да дәртләнебрәк эшләргә стимул бирде ул.

Эльвира МОЗАФФАР

– Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәр турында түкми-чәчми балаларыбызга тапшыру – хәзерге буынның төп вазифасы. Радио һәм телевидение, урам йогынтысы балаларның аңына, рухына әдәпсезлек үрнәкләрен сеңдергән заманда, милләтнең гасырлар буе формалашкан тәҗрибәсе, әхлак кагыйдәләре югала бара. Менә шуның өчен дә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә халкыбыз хәзинәләре нигезендә нәниләрдә милли үзаң тәрбияләргә тырышабыз, – ди 162нче балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе Рузилә Абдуллина.

Балалар бакчасында татар телен үстерүдә шактый эш алып барыла. Һәр чара федераль дәүләт стандартларына туры китерелеп, балаларның психологиясен тоемлап оештырыла. Беренче чиратта балаларны шәхес буларак тәрбияләүгә зур урын бирелә. Балалар язучылар, журналистлар белән очрашып тора. Аларда «Шәһри Казан» газетасы, «Салават күпере» журналы хезмәткәрләре еш кунак була. Язучыларның иҗатына багышлап, төрле чаралар оештырыла. Әле менә күптән түгел генә Габдулла Тукай айлыгы кысаларында, татар теле тәрбиячесе Надия Вәлиева иҗат иткән «Салават күпере» дип аталган әкият карадылар. 162нче балалар бакчасында «Идел буе халыкларының гореф-гадәтләре аша – татар телен үстерү» проекты эшләп килә. Балалар Иделдән Уралга кадәр яшәүче халыкларның гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнәләр.

– Мең кабат укыганчы, бер тапкыр күрү яхшырак, диләр бит. Психология ягыннан килсәк тә, баланың баш мие губка сыман сеңдерә. Төрле образларга кереп уйнау, тою, күрү аша истә калдырырга җиңелрәк, – ди Рузилә Абдуллина.

Балаларның чараларында әти-әниләрнең катнашуы да сөендерә. Әйтик, беренче төркемнән Азалия Абдрафыйкова һәрчак әнисе белән бергә рәсемнәр ясап килә. Әминә Җиһаншинаның әнисе төрле кул эшләренә оста. Лилия Ташхуҗаева гаиләсе тәмле тортлар белән сыйлый. Рәис Вәлиев, Әмир Исмәгыйлов, Аделина Ганиева үзләре китапчыклар ясый. Кирилл Михайловны бакчаның «йөзек кашы» дип йөртәләр. Бу талантлы малай – бик күп конкурслар җиңүчесе: «Сәләтле бәләкәч», «Синяя птица»,«Йолдызлык», «Җырлы-моңлы балачак» дисеңме. Әле шулар өстенә, «Тапшырылмаган хатлар» кинофильмында да төште.

Татар телен үстерүдә әти-әниләр белән тәҗрибәле тәрбиячеләрнең кулга-кул тотынышып эшләүләре уңышлы нәтиҗәләр бирә.

– Балалар – безнең көзгебез кебек. Барысын да үзләрендә чагылдыралар. Шуңа да киләчәк буын турында кайгыртып, балаларны тәрбияле, әхлаклы итәргә тырышыйк, – дип эшли 162нче балалар бакчасы тәрбиячеләре.

Каһарман әдип исеме белән

Бүген бөтен китапханәләр диярлек, балалар укымый, дип зар елаган бер заманда, каләм тотып, иҗатка омтылучы малай-кызларның саны елдан-ел арта. Казан шәһәренең 20нче гимназиясе менә инде дүртенче ел рәттән үткәрә торган «Алиш варислары» республика конкурсына килгән хат-язмалар да шул хакта сөйли.

Элек әлеге конкурста җиңүчеләрнең иҗат җимешләре юка гына китапчык итеп нәшер ителсә, хәзер инде ул жанрларга бүленеп, берничә калын китап булып дөнья күрә. Конкурсның быелгысына да кочак-кочак шигырь-хикәя килгән. Хәзер бит аларны бастыру өчен балалар матбугатында урын аз бирелә, мондый конкурсларда катнашып, бик дөрес эшләгән яшь иҗатчылар. Грамота, Дипломнардан торган портфолио укучыларга да, укытучыларның үзләренә дә бик кирәк. Ә аны тик торган өчен генә китереп бирмиләр. Шундый форсат тудырганнары өчен, бәйгене оештыручыларга рәхмәттән башка сүз юк. Чөнки Тукай әйтмешли, «күкрәгендә иҗат утын сау йөрткән» мөгаллимнәр аз түгел бездә. Бәхеткә, аларның күбесе, шушы утны шәкертләре җанында да кабызып, шигъри учак яга. Шулай итеп, укучыларының да иҗади осталыгын арттыра, үзләре дә дан ала.

«Нәрсә языйм?» дип аптырап торасы да түгел. Тема аяк астында гына, дөресрәге, күктә, җирдә һәм җанда. Күңел-җаны буш булса, аңа беркайчан да илһам кошы килеп кунмый, андый кеше беркайчан да кулына каләм алмый. Алган очракта да, ул каләмнән күңелгә үтеп керерлек әсәр тумый. «Җаннан чыккан гына җанга барып җитә», – ди безнең халык. Аннары каләм ул аны тоткан хуҗасы белән бергә хакыйкатьне дә эзләшә бит әле. Шуның белән кыйммәт тә ул. Тормыш хакыйкатен! Шуңа да каләмле балага игътибарлы, аңа хәерһахлы булырга тырышырга кирәк.

– Безгә Алиш исеме килеште, – диде республикабызның төрле районнарыннан җыелган малай-кызлар һәм аларның укытучылары алдында чыгыш ясап, бүген үзенә кунаклар чакырган гимназиянең директоры Рәхимә Арсланова. – Әйтерсең лә, ул безнең һәр эшебезне хуплап, үз фатихасын биреп тора. – Гимназиябезнең 1000000 сумлык грант отуын да, ә бер укытучыбызның Россия күләмендәге бәйгедә җиңеп чыгуын да шуның белән бәйлибез.

Әлеге сүзләргә бүгенге иҗат бәйрәменә килгән Алишның туганнары аеруча сөенде (рәсемдә). Алар – бу гимназиянең якын дуслары, биредәге «Алиш варислары» музеен экспонатлар белән дә баетучылар. Иҗат бәйгесенең быелгысына да бик теләп килгәннәр. 36 яшендә фашист балтасыннан башы киселгән җәлилче туганнарының исемен шулай мәңгеләштерер өчен тырышып йөргән әлеге гимназия коллективына бик рәхмәтле алар. Конкурста төрле урыннар яулаган малай-кызларга Алиш туганнары кулыннан бүләкләр алу гомергә онытылмаслык мизгелләр булды. Киләчәктә андый бәхетләләр тагын да артыр дип өметләнергә җирлек бар. Алишның кардәшләре, әлеге «Алиш эзләреннән» дигән бәйгегә Халыкара статус бирергә кирәк, дигән фикер белән чыктылар. Алиш исемен йөрткән 20нче гимназия урнашкан Пионерлар урамын Алиш урамы итәселәре, ә аның ишегалдында чәчәкләргә күмелгән һәйкәлне дә күрәселәре килә аларның. Барлык яхшы эшләр дә башта бер игелекле җанның хыялында бөреләнә бит. Бергәләп тотынсак булыр да. Башта гимназиядә «Алиш варислары» музее ачылды, аннары аның исемен алу өчен күпме тырышып йөрделәр. Анысы да булды. Болары да тормышка ашар, иншалла. Исемнәрен мәңгеләштерерлек батырлар булганда, кулдан килмәслек эш түгел ич. Теләк кенә кирәк. Ә теләк-омтылыш, иҗади тормыш әлеге гимназия коллективында башкаларга да бүлеп бирерлек. Ул көнне Татарстаныбызның төрле районнарыннан, хәтта иң ерак Актаныш һәм Мөслимнән килүчеләр дә моны күреп, каләмнең хакыйкатьне эзләшүенә тагын бер кат инанып киттеләр.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ИҖАТ

Сания апа, без сезне яратабыз

Кайсы төбәктә генә яшәмәсен, уңышларга ирешкән, хөрмәткә лаек һәр улын, кызын барлап: «Безнеке!» – дип горурланып яши авыл халкы. Әлбәттә инде очрашуларның да иң эчкерсезе, ихласы туган җирдә узганы була. «Оч ирекә, җырым», «Пар алма», «Гәрәбә» китаплары һәм 100гә якын популяр җыр тексты авторы Сания Әхмәтҗанова – безнең Арча районының Курса Почмак авылы кызы.

Казанда 20 елга якын башлангыч сыйныфлар һәм татар теле, әдәбияты укытучысы булып эшли. Соңрак укытучылар журналы булган «Мәгариф»тә 17 ел бүлек мөхәррире һәм җаваплы сәркатиб вазифаларын башкара, хәзерге вакытта Сания Әхмәтҗанова – «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татарча хәбәрләр редакциясе мөхәррире.

Шушы көннәрдә Курса Почмак урта мәктәбендә авылдашыбыз, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һади Такташ исемендәге әдәби бүләк иясе шагыйрә Сания Әхмәтҗанова белән очрашу булды. Кунагыбызны балалар дулкынланып көтеп алды. Аның җылы күз карашын күреп, йомшак тавышын, алтынга тиң фикерләрен ишеткәч, балаларыбыз да ачылып китте. Алар да шагыйрә апаларына җавапсыз калмадылар: үз талантларын күрсәттеләр. Сания Әхмәтҗанова балалар язган шигырьләрне, алар башкаруында җырларны бик игътибар белән тыңлады.

– Фикерләрегез матур, арагызда каләмен нык тотып язучылар да бар. Шулай да кабатланмаганрак темаларны алырга тырышыгыз, башкалар күргән-белгәнне үзегезчә әйтегез, – дип, үз киңәшләрен дә бирде.

Очрашуга килгән авылдашларыбыз арасында Сания апаның иҗатын яратучылар, шигырьләрен яттан белүчеләр, җырларын гел күңел түрендә йөртүчеләр бихисап икән. Аларны тыңлап та хис-тойгыларга бирелеп утырдык. «Ватаным Татарстан» газетасында дөнья күргән «Толым» бәян-хикәясенең китап булып басылып чыгуын да теләде авылдашлар.

– Шундый якташларың, туганнарың, хөрмәт итүче авылдашларың булганда, ничек язмыйсың инде! Моның кадәр хөрмәт, ихласлык, чын авылча ярату һәр иҗат әһеленә дә үз вакытында килеп ирешмидер. Бу юлы сез минем иҗатымны, үземне генә түгел, миңа белем биргән мәктәбемне, укытучыларымны һәм үзегезне дә олыладыгыз, – дип, укучыларга һәм укытучыларга рәхмәтен белдерде Сания ханым.

Очрашудан һәркем рухи азык алды. Бу матур хисне һәркайсының күз карашыннан аңлап була иде. Мәктәбебез директоры Нурзилә Сабирҗанова укучыларыбызның чыгышларына соклануын һәм авылдашыбыз Сания ханымга олы рәхмәтләрен белдерде.

«Шәһри Казан» газетасы аша Сания апаны туган көне белән котлыйбыз. Аның җырлы-шигырьле сәфәрләрендә яңа табышлар, иҗади күтәрелеш, бәрәкәтле озын юл телибез. Гел шулай яшьнәп-җемелдәп, бик күпләрне моң тылсымына әсир итеп яшәргә насыйп булсын. Сания апа, без Сезне бик яратабыз.

Курса Почмак мәктәбе коллективы исеменнән,
Ләйсән ШАКИРОВА,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

«Күңелем түрләреннән чыга җырларым»

Юл төшеп Бауманга барып чыксак, без бу мәһабәт «Чәй йорты»на керми калмыйбыз. Тәмле өчпочмаклар, чәй, гаҗәеп чисталык, матурлык, гөлләре-чәчәкләре өчен дә түгелдер, мөгаен, сине һәрчак елмаеп: «Әйдәгез түрдән узыгыз, чибәр апакайлар!» – дип каршылаучы ханымнарның сөйкемлелеге тартадыр.

Бер кергәндә танышып сөйләшеп киттек. Гөлсирә белән Әлфирә икән үзләре. Әлфирәсе, машалла, әле җырлый да, җырлар да яза икән. Соңгы вакытта телевизордан да еш күренә торган Эльмира Сөләйманова башкара торган «Балан ачы шул, балам!» җырының авторы булып чыкты ул.

– 130 җыр яздым инде, җырларымны Илдар Әхмәтҗанов, Миргаяз Шәрәфиев, Рәшит Сөләймановлар башкара. Әле Хания апа белән дә очрашырга сөйләштек, – дип сөйли Әлфирә.

– Соң шулай булгач, нишләп йөрисең соң монда? – дим.

– Җыр ул – күңел эше, рухи дөньяң, ә эшең – дөнья көтү чарасы, үзеңнең кирәклегеңне тану ысулы. Бер генә эшнең дә кимчелеге-хурлыгы юк, апам! Һич кенә дә хурланмыйм, «Чәй йорты»быз – үзәктә, мактаулы кафе. Милли ризыклар яратучылардан көн-төн рәхмәтләр генә ишетәбез. Җырларым исә барганда да языла, кайтканда да, өйгә кайтуга, диктофонга гына төшерәсе кала. Алланың рәхмәте бу, олы нигъмәте. Юкса өч мәртәбә үлемнән калдым бит. Сабырлыгыма, түземлегемә күрә биргәндер газиз Аллаһы Тәгаләм бу бүләкне…

Әлки районының Иске Салман авылы кызы ул. Танылган балта остасы, матур җырлаучы Заһид белән бик уңган-булган Гөлсем гаиләсендәге төпчек бала. Дүрт абыйсы һәм Гөлсирә апасының кочагыннан төшми үсә.

Мәктәптә укыганда ук, шигырьләр яза башлый кызчык, шул ук вакытта әти-әнисеннән өйрәнгән җырлар белән концертларда катнаша.

10нчы сыйныфны тәмамлагач, Казанның кооператив техникумына укырга керә. Аннан кайткач, авыл кибетендә эшли, яшь көе кияүгә чыга. Ашыкканын-ялгышканын бик тиз аңлый да бит… Кызы Эльмира туа. Бәлки тормышлары җайланыр дип, Төрекмәнстандагы хәрби хезмәттәге Хаҗип абыйсы үз янына чакыра. Барып заводка эшкә урнашуга, бүлмә бирәләр. Өч айдан өч бүлмәлегә күчәләр. Икешәр смена эшлиләр, акча да керә, тик аралар гына катмарлы. Ул да түгел, 50-60 градус эсселектә кызлары авырый башлый. Гөлсирә апасы килеп, баланы авылга алып кайтып китә. Әлфирә өчен инде тормышның яме калмый, баласын сагына. Ахырдан Казанга кайталар. Улы Илсур туа, ә яшәүләренең барыбер рәте булмый. Аерылышалар. Ишегалды себерүче булып эшкә урнаша. Тәкъдир. Өч елдан фатирлы була Әлфирә. Үзләре янындагы тегү фабрикасына эшкә урнашкач та, тырышлыгын тиз күрәләр. Бусы инде планыңны үтәү генә түгел, ә бригадаң өчен, теккән әйберләрнең сыйфаты өчен җавап бирү. Үз эшенең остасына әйләнә ул монда. Ә «Оргсинтез» кебек олы оешмага барып кергәч, тагын да кирәклерәк һөнәр – штукатур-маляр эшен үзләштерә. Бу вакытта инде Әлфирә Анатолийга кияүгә чыккан була. «Биш балаң булса, биш балаң белән дә алам», – дигән ул. Бу никахтан кызлары Эльза туа. (Хәзер инде олы кызы медицина көллиятен тәмамлап, шәфкать туташы, Илсуры исә КАИда укый.) Ул тугач, җир алып бакча ясыйлар һәм үз куллары белән ике катлы өй төзеп яши башлыйлар. Әлфирәнең кулыннан килмәгәне юк. Ремонт дисеңме, беседка, бассейн кирәкме – үзе дизайнер, үзе төзүче. Тик борчу-хәсрәтләр дә янда гына шул. Авылга кайтуларының берсендә, мунчадан чыгуга, Әлфирә аңын җуеп егыла. Шунда искиткеч яктылыкка баруын тойган ул. Бөтен дөнья яктылыкта, имеш. Йөзләре ак кардай, йөрәк тибеше дә сизелми, ди. Анатолий елый-елый өйгә күтәреп кертеп салган хатынын. Күпме вакыт узгандыр, аңына килсә, бите буйлап чишмәдәй тир ага. Менә шунда башына көе белән бергә шигъри юллар килә:

«Балам бәгърем!
Яшьләр ага мөлдер-мөлдер,
Берничек тә булмый туктатып...»

– Күк капусы ачылгандай хис иттем, башка берни белән аңлата да алмыйм, белмим дә, бәлки мәрткә китү булгандыр, – дип сөйли Әлфирә ул вакыйга турында. – Ни булса да, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте! Шуннан соң мин Коръән сүрәләренә тагын да ныграк ябыштым,– ди ул.

Уй-хыялларың, өметләрең гел яхшылыкта булса да, язмыш юлында упкыннар да әзерләп куя икән шул. Алдан ук ниятләп, авылларына корбан чалырга кайталар. «Җиде кыз чишмәсе» дигән бик матур урында әби-апалар җыелып, мул табынлы Коръән мәҗлесе оештыралар. «Олы бурычны үтәдек, Аллага шөкер», – дип шатланышып кайтып килгәндә, «Җенле җир» борылмасында машина чокырга барып төшә. Шөкер, башкаларга берни булмый, тик Әлфирә кымшана да, дәшә дә алмый. Алексеевск хастаханәсенә илтеп салалар. Биш көннән Казанга. Республика клиник хастаханәсендә томография ясап, умыртка баганасы сынганлыгын ачыклыйлар. Ике ел дигәндә, аякка баса тагын. Эшеннән кайта да шигырьләре тулы дәфтәрен, җырларын күтәреп, җырчылар янына китә. Миңгол Галиев белән шулай дуслаша.

– Ул, эше күплеккә карамый, һәрчак кабул итә, киңәшләрен бирә, җыр башкару дәресләре биреп, мине тәки җырчы баскычына бастырды, – ди Әлфирә.

Инде әнә уңышлары да күренә. Яңа елы уңышларга мул булачагына ышана Әлфирә Гайнуллина. Беренче көннәрендә үк «Тәртип» радиосында аның иҗат юлына багышланган матур эчтәлекле тапшыру яңгырады, үзе сөйләде, җыр башкарды. Җырлары камил, өметле. «Инде клип чыгарам, китап бастырам, Аллаһы боерса», – дип җиң сызганып, иҗат дулкынында кайный. Бирсен Ходай дип телик!

Мөслимә ШӘФЫЙК,
Казан.

Өммәтне алга әйдәүчеләрнең хаклары

Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,
Түбән Кама җәмигъ мәчете имам хатибы

Әгәр Аллаһы бер бәндәсенә мал-мөлкәт бирсә, әлбәттә, ул башкалар белән бүлешә бельергә тиеш. Аллаһы бирүчегә бирә, саранныкын тартып ала. Җәмгыятьтә көчлеләрнең ярдәменә мохтаҗ кешеләр шактый. Ислам динендә ярдәмгә мохтаҗ булган катламны кайгырту һәрвакыт күз уңында булган.

Сөбханаллаһ, шәригатьтә каралган хакларга күз салыгыз: фәкыйрьмескеннәр, тол хатыннар, атасыз калган ятимнәр, юл мәшәкатенә дучар мосафирлар, бәла-казага тарыган кешеләр, залим тарафыннан кимсетелгәннәр (мәзлүмнәр), урын өстендәге хасталар, чал чәчле өлкәннәр һәм сабыйлар хакы... Болар турында галимнәр күпме китап язган, имамнар мөнбәрләрдән күпме вәгазь сөйли?!

Әмма бу вәгаземдә ярдәмгә мохтаҗ катламның хакы түгел, киресенчә, шул мохтаҗларга ярдәм кулы сузучыларның хаклары турында сөйләргә ниятләдем. Әйдәгез, зәгыйфьләр түгел – ә көчлеләрнең, арттан иярүчеләр түгел – башкаларны ияртеп баручыларның, өммәтне, милләтне алга тартучыларның хакларына бераз тукталып китик. Күп нәрсәне белеп торучы «Гугл» хәзрәткә «зәгыйфьләр, фәкыйрьләр хакы» дип кертсәң, шулкадәр күп мәгълүмат табасың. Әмма «байлар хакы», «көч-куәт ияләре хакы» дигәч, интернетта әллә ни күп нәрсәгә юлыгып булмый.

Ни өчен дини язмаларда зәгыйфь катламның хаклары турында күп языла, ә көч-куәт ияләренең хаклары бик аз искә алына? Ә бит, нәрсә булса да, шуларга чабабыз: «Зәкятеңне түләдеңме? Зәкят – һәр мөселман баена фарыз», «Әйдә, мәчет салырга ярдәм ит әле!», «Авырып ятучы кардәшебезгә ярдәм кирәк», «Бер балага операция ясатабыз», «Бер гаиләнең өе янып беткән»... Әле моның ише хәйрия эше белән хөкүмәт өлешен түләгәннән соң гына шөгыльләнеп була бит. Хөкүмәт тә эш адәмнәрен артык иркәләми: «Декларация тутыр», «Салымыңны түлә», «Сабан туена өлеш керт», «Яңа елга чыршы куй», «Машинаңа күбрәк төягәнсең, ясагыңны түлә!» һ.б.

Кыскасы, «Сез эшкуарлар безнең алда муеннан бурычлы». Монысы аңлашыла, ә без аларга нәрсә тиеш икән? Тупны бер капкага гына тибү дөрес түгел, һәрнәрсәдә гаделлек кирәк. Көч-куәт әһелләренең, өммәтебезгә хезмәт итүчеләрнең җәмгыять, халык өстендә нинди хаклары бар?

Еш кына: «Ходай каршында барысы да тигез», – дигән сүзне ишетергә туры килә. Шиксез, Аллаһы каршында, Аның шәригате каршында – кешеләр тигез. Акчасы күп яки дәрәҗәсе зур булганга карап кына, беркемнең дә өстеннән фарыз төшми, хәрәм дә хәләлгә әйләнми. Әмма һәр урында, һәр җирдә кешеләрнең барысын да бер калыпка салып тигезләү гаделлек булмый. Сөекле Пәйгамбәребез: «Кешеләргә үз урыннарын бирегез», – дигән (Әбү Даут риваяте). Динебез һәркемгә, үз дәрәҗәсенә карап, лаеклы урынын бирергә өйрәтә. Өлкән кеше белән яшь кеше, галим белән надан, тырыш белән ялкау тигез дәрәҗәдә була алмыйлар. Шуңа күрә кайбер кешеләрнең: «Диндә барысы да тигез», – дигән сылтау белән хөрмәт иясен хөрмәтләмәүләре аларның наданлыгына һәм әдәпсезлегенә кайта.

«Тарихны шәхесләр ясый», – дигәннәр. Аллаһы Үзенең хикмәте белән һәр милләт, һәр халык өстеннән аларны җитәкләүчеләрне – алга әтәрүче яки упкынга илтүче шәхесләрне куя. Аларга арбаны тарту өчен көч-куәт, мал-мөлкәт бирә. Бу – Аллаһы куйган тормыш кануны булып тора. Сөекле Пәйгамбәребез хәтта сәфәр кылганда да арадан кемнедер җитәкче итеп куярга, аңа ияреп кушкан һәм: «Әгәр өч кеше сәфәргә чыксалар, арадан берсен әмир итеп сайласыннар», – дигән (Әбү Даут риваяте).

Төгәл 100 ел элек илдә җәмгыять системасы үзгәреп, социализм килгәч, «Без бар халыкны тигезлибез!» – дип, гади халыкны өметләндерәләр. Хәзерге Сарман районының Яхшыбай авылында

ҖОМГА ВӘГАЗЕ

(бабаларым шушы авылдан) XIX гасыр азагы-XX гасыр башында авылның тоткасы булган, тирә-юньдәге мәчет-мәдрәсәләргә ярдәм итүче Мортаза Мусин яшәгән. Үзе вафат булганда, васыять итеп, дин-мәчетләр өчен 90 мең сум вакыф акчасы калдырган (Аллаһы милләттәшебездән разый булсын). Шул Мортаза хаҗи мәшһүр «Эль-Иткан» тәфсирен язган Шәйхелислам Хәмидине үз авылында имам итеп тоткан, хезмәт итү өчен аңа барлык мөмкинлекне тудырган. «Гаетләрдә ат арбасына күчтәнәчләр төяп, авыл буйлап тарата иде», – дип сөйли торган булган бабамның әнисе. Хөкүмәткә сәвит власте килгәч, шул авылның бер кешесе әйтә икән: «Бу сәвит властe халыкны тигезлибез дигәч, мин ничек Мортаза кадәр мал асрый алыйм, аның кадәр иген үстерә алыйм дип бик кайгырган идем. Безне – аларга түгел, ә аларны безгә тигезләүләрен ишеткәч тынычландым».

Чыннан да, нишләптер, коммунистлар ярлыларны байларга тигезләргә ашыкмадылар. «Әйдә тугын, эшлә, тырыш, син дә бай булырсың», – дип, халыкны өскә таба тартмадылар. Киресенчә, өстәрәк булганнарны аска тартып төшерделәр һәм байларны хәерчегә әйләндерделәр. «Кулак», «халык дошманы» кебек гаепләүләр тагып, кулыннан эш килгән, көче булган, уйлый-фикерли белгән күпме кешене изделәр! Үзен һәм гаиләсен генә түгел, туган авылын, милләтен дә яшәтә алган кешеләрне юкка чыгардылар.

Аллаһы Тәгалә, Үзенең кешелеккә булган соңгы мөрәҗәгате белән, ахыр илчесен җибәргәч, аның янына җир өстендәге иң хәерле кешеләрне җыя: хатыны Хәдичәне, Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Гайшә һ.б. Әлеге шәхесләр Пәйгамбәргә иң зур терәк булалар һәм ислам динен офык-кырларга таратуда зур өлеш кертәләр.

Бүген дә ил, милләт, халык, дин, мәгърифәт эше шундый ирләрдән һәм хатыннардан башка бара алмый. Һәр эшнең, һәр уңышның нигезендә – кемнәрнеңдер зур хезмәте, йокысыз төннәре, эчкерсез фидакарьлеге. Казан ханлыгы алынганнан соң, татар мөселман өммәте 500 ел изелеп яшәсә дә, һәр заманда милләтебезнең узаңы, иманы өчен көрәшүче ирләр һәм хатыннар була. Узган гасыр башында гына да татар галимнәренең күпме хезмәт язганнарын күрәбез. 1905 елда бераз дин иреге бирелгәч, милләт телендә күпме китап, журнал һәм газета чыгарырга өлгергәннәр. Кемдер – зирәк акылы, үткен каләме, ә кемнәрдер хәләл акчасы белән татар халкының меңьеллык кыйблаcын саклау өчен көрәшкән. Кызганыч, бүгенге көндә гади татар кешеләре түгел, хәтта дин өлкәсендә кайнашып йөрүче шактый хәзрәт-абыстайлар да Шиһап хәзрәтләрне, Риза казыйларны, Максуди, Хәмиди хәзрәтләрне, Галимҗан мөфтиләрне бик аз беләбез. Алар рухына догаларны аз кылабыз.

Галим ни эш кылыр, әгәр аның янәшәсендә мал-мөлкәт ияләре булмаса?! Карагыз, татар байлары күпме хезмәт кылганнар. Ырынбурның Каргалы авылыннан чыккан Хөсәеновлар 100ләп мәчет-мәдрәсә салдырганнар, татарның мәгарифен үстерү өчен көч түккәннәр. Шул ук яклардан чыккан бертуган Рәмиевләр, Казан байлары Юнысовлар, Апанаевлар һ.б... Аларның һәркайсына, гаилә әһелләренә бездән хәер-дога булсын.

Гомум милләт бурычларыннан инде үзебезнең кечкенә мәхәлләләребезгә күчсәк, дин, гыйлем, хәйрия эшендә нинди генә алга китеш булса да, аның башлангычында аерым кешеләр тора. Әлбәттә, һәркайсыбызның өстендә милләткә хезмәт итүче, өммәтне алга әтәрүче көч-куәт ияләренең, мал-мөлкәт әһелләренең хаклары бар һәм аларны үтәмәү безнең тарафтан аларга карата золымлык була.

Дингә хезмәт итүче мал-мөлкәт, көч-куәт ияләренең берничә хакын искә алып китик:

РӘХМӘТЛЕ БУЛУ

Әгәр мөселман кемгәдер изгелек кылса, ул Раббысының ризалыгын өмет итә, ә моның өчен үзен мактаганнарын да, рәхмәт укыганнарын да көтәргә тиеш түгел. «Изгелек ит тә суга сал», диелә мәкальдә. Әмма мөселманга кемдер изгелек кылса, аңа: «Ярый, миннән рәхмәт көтмә инде, Раббың рәхмәтен салыр әле», – дип әйтү дөрес түгел. Пәйгамбәребез: «Кешеләргә шөкер итмәгән – Аллаһыга да шөкер итми», – дигән (Тирмизи җыентыгында). Әгәр Аллаһы бер бәндәсенә ниндидер нигъмәт бирергә теләсә, ул нигъмәтнең аңа ирешү юлын сайлый, сәбәбен һәм сәбәпчесен булдыра. Сиңа Раббыңның нигъмәтен ирештерүчегә шөкер итүең Раббыңа шөкер кылуың була. Сиңа кемдер файдалы эш кылса, синең ул кешегә рәхмәтле булуың аны җибәрүче Раббыңа рәхмәтле булуыңны күрсәтә. Ул кешегә рәхмәтсез булуың Аллаһыга рәхмәтсезлегең булып чыга. Шуңа күрә Аллаһының иң бөек нигъмәте булган хак гыйлемнәрне безгә ирештерүче пәйгамбәрләргә, галимнәргә рәхмәтле булу, аларны ярату – өстебездәге бурыч. Аллаһы биргән гомер нигъмәтен тапшыруда сәбәпче булган ата-ананың ризалыгын алу да Аллаһының ризалыгын алуга сәбәп була. Хәдиснең икенче риваятендә: «Кешеләрнең Аллаһыга күбрәк шөкер иткәне – кешеләргә дә күбрәк шөкер итүче була», – дип килә (Имам Әхмәт, Табәрани риваятьләре).

Еш кына үзебезгә изгелек кылучыларның кем булуларын белмибез дә, ул хакта уйламыйбыз һәм аларга шөкер дә итмибез. Адәм баласының бәласе – кешенең йөз изгелеген дә бик тиз оныту, ә бер кимчелеге булса да, хәтердә калдыру. Тормышында бер эш тә кылмаучы гына абынмый. Нәрсәдер эшләргә тырышучылардан гаеп эзләргә, аларның гайбәтләрен сөйләргә яратабыз. Бер журналистның гел бер җитәкчене хурлап язуын күргәч, аңа шалтыратып: «Абый, ул түрәнең игелекле эшләре дә күп бит, ни өчен гел яманлап кына язасың», – дип сорадым. Ул миңа: «Хәзрәт, федераль акчага кылынган эшне изгелек дип санамыйм, ул аны болай да башкарырга тиеш», – дип, авызны ябып куйды. Әнә шулай уйлау – тәрбиясезлегебез, җәмәгать.

→ Ахыры бар.

Нияз Бишбалта төзеде.



Чайнворд «Физика»

1. Химик элементның төп сыйфатларын саклаган иң кечкенә кисәкчә.
2. Физиканың пространствода җисемнәр хәрәкәтен китереп чыгара торган көчләрне, законнарны өйрәнә торган фән бүлеге.
3. Төрле законнар ачкан итальян физигы (1776-1856).
4. Электр каршылыгын үлчәү берәмлеге.
5. Ритмлы хәрәкәтне тәэмин итү өчен, бер башы хәрәкәтсез ноктага беркетелгән, авыр башы асылынып, тирбәлеп торган җайланма.
6. Рус коралы көчләренең алга китешенә зур хезмәт куйган физик (1894-1984).
7. Электр тогы көчен үлчәү берәмлеге.
8. Шотландиядән Яңа Зеландиягә күчеп килгән атаклы физик (1871-1937).
9. Механикада җисемнәрнең хәрәкәт законнарын өйрәнә торган бүлеге.
10. Тирбәлеп торган җисемнең тигезлек ноктасыннан иң нык тайпылган хәле, тирбәлеш киңлеге.
11. Әйбернең үлчәүгә салып билгеләнә торган сыйфаты.
12. Нәрсәнең дә булса электрлану хәле.
13. Грек физигы, Сиракуза инженеры, механикага нигез салучыларның берсе (б.э.к.287-б.э.к.212).
14. Берәр нәрсәдә дымның күләме (микъдары).
15. Нинди дә булса энергиянең иң кечкенә өлеше яки кисәге.
16. Хәрәкәт итә торган җисемнең пространстводагы юлы.
17. Нинди дә булса чыганактан чыккан нурлар.
18. Киеренке булу.
19. Электр микъдарын үлчәү берәмлеге.
20. Инглиз физигы, математигы, астрономы (1612-1727). Механиканың өч законын уйлап табучы. Көзгеле телескоп авторы.

Җаваплар.
1.Атом **2.**Механика **3.**Авогадро **4.**Ом **5.**Маятник **6.**Капица **7.**Ампер **8.**Резерфорд **9.**Динамика **10.**Амплитуда **11.**Авырлык **12.**Корылма **13.**Архимед **14.**Дымлылык **15.**Квант **16.**Траектория **17.**Яктылык **18.**Киеренкелек **19.**Кулон **20.**Ньютон.

Өйрәнгәнчә

көлсәң – көл

Соңгы вакытта Фәрит белән Алия бик матур яши башладылар. Әллә 20 елдан артык «Кем кемне җиңәр?» дип астыртын алып барган сугыш икесен дә туйдырып җибәрде, әллә балаларның берәм-берәм үсеп аякка басуы үзенекен итте – тынычланды аларның тормышы. Талаш юк, кычкырыш юк, китапларда язганча, «Хәерле иртә!», «Тыныч йокы!», «Ашың тәмле булган, кадерлем»...

Баштагы мәлне Алиянең кирәксә-кирәкмәсә чәрелдәве туктауга, үзен ничектер ятим калгандай сизгән Фәрит соңгы вакытта аракыдан да бизә башлады. Ә элегрәк иренең атнага бер булса да дуңгыз булып мыркылдаганчы эчүенә ияләшкән Алия үзенең нишләптер чәрелдисе килмәвенә аптырады.

Йортка таң алдыннан таллар арасыннан бормаланып аккан елгаларда гына була торган тынлык инде. Сабырлык рухы белән сугарылган көннәрнең берсендә, тынычланып, тәмләп кенә чәй эчкән мәлдә, үз уйларына чумып утырган Алия мышный-мышный чәй шопыручы Фәриткә карап әйтеп куйды:

– Түбән оч Гамир кичә, базарга барып, хатынына егерме җиде канәфер чәчәге алып кайткан. Тегесенә егерме җиде генә яшь икән әле.

Фәрит бушаган чынаягын хатынына таба сузды.

– Аңгыраның аңгырасы инде. Барлы-юклы акчасын да шуныңише юк-барга әрәм итеп бетерә, – диде ул, яңадан чәйгә тотынып.

Алия нигәдер сискәнеп китте.

– Ә менә синең миңа үз гомереңдә бер генә тапкыр да чәчәк бүләк иткәнең юк, Фәрит, – диде ул, тәрәзәгә карап. – Егерме елдан артык торсак та...

Фәрит чынаягын читкәрәк алып куйды:

– Ә синең үз гомереңдә миңа махмырдан, бер илле грамм булса да, аракы салып биргәнең бармы соң? Гамир үзе аңгырарак булса да, аны хатыны ачы балдан өзми ичмасам. Андый хатынга чәчәк кенә түгел, әллә нәрсә дә алып кайтып тоттырырсың.

– Әйсәнә, – диде Алия, кулын селтәп. – Сиңа әйткән мин тиле...

– Кара әле, Алия, – диде Фәрит, тавышын күтәрмәскә тырышып. – Хәтерлисеңме, теге сыер икене бозаулаган елны мин сиңа нинди тәмле хушбуй бүләк иткән идем?

– Иткән идең, иткән идең. Аннары шул игезәк бозауларны «юганда», аракы житеп бетмәгәч, Җәмил белән шуны үзегез үк суга бутап эчкән идегез. Өч көн йөрдең аннары, киемнән, бөтен җирдән хушбуй исе килә дип.

Алия кинәт сулкылдап куйды. Фәрит авыр итеп бер сулап алды.

– Син бигрәк инде, Алия, – диде ул. Аз гына күзен йомып торгач: – Ә хәтерлисеңме, мин сине шәһәргә концертка алып барган идем? Әллә театргамы әле?

– Менә, менә, – Алия ничектер җанланыбрак китте. – Үзең хәтерләмисең дә шул, чөнки анда баргач та, син шул шәһәр хатыннарының ботларыннан күзеңне ала алмадың. И-и, гомер буе кадеремне белмәдең инде-е. Йә эчтең, йә читкә карадың.

Кинәт Фәритнең күзләре әллә нәрсә эшләп китте. Ул утырган урыныннан әкрен генә торып басты да хатынына таба иелде.

– Ә син минем кадерне белдеңме соң? – диде ул, ниндидер ят тавыш белән. – Мин бу йортны салдым, гомер буе калхузда эшләдем. Миндә чәчәк кайгысы булды дип уйлыйсыңмы әллә?

Алия нигәдер урындыгын читкәрәк шудырып куйды.

– Син эшләсәң, мин балалар үстердем, – диде ул, еламсырак тавыш белән. – Өйдә дә тик ятканым булмады. Ашсыз тотмадым берегезне дә...

Фәрит, гомердә булмаганны, өйдә үк тәмәкесен кабызды.

– Балалар кемдә дә үсә ул, – диде ул, хатынына нәфрәтле караш ташлап. – Әнә көтүче Сабирҗан абзый, хатыны булмаса да, ачтан үлми. Әле корсагы минекеннән дә зуррак, битләре дә елкылдап тора. Ашарга пешердем, имеш... Пешермәскә иде. Йөрергә иде әнә сыер саварга.

Алия дә урындыгыннан торып басты. Аның күзләреннән дә ут бөркелә иде.

– Нәрсә, өйне үзем генә салдым диясең киләме әллә? Ә минекеләр күпме булышты?! Әле ул әнүләреңнең белән ничек эшеңдә асрадылар үзеңне?..

Фәрит тәмәкесен өстәлдәге чынаякка тыгып сүндерде дә идәнгә үк атып бәрде.

– Синекеләрнең булышуы шул эчкәндә генә булышу иде бит ул, – диде ир, хатынына якынрак килеп. – Алар эчкән аракыны шул ук Җәмилләргә эчергән булсаммы?!

... Бераздан беренче чынаяк идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде. Аннары урындыклар ауды, өстәлдәге савыт-саба әскәтер белән бергә идәнгә төшеп тапталды. Тәрәзәләр арасына эленгән күкеле сәгать кыйшайды. Аннары ялтыравык электр самавыры тәрәзәдән тышка очты. Алия гомердә булмаганча чәрелдәде, ә Фәрит, яланаякка галош өстерәп, аракы эзләргә чыгып китте.

Ир белән хатын арасында озакка бармаган тынычлык чоры, ниһаять, ничек башланса, шулай бетеп, алар өйрәнгәнчә яши башладылар...

Гамирның бер бәйләм чәчәге бөтен эшне харап итте.

Илфак ШИҺАПОВ.

Газ кулланучы котельный хуҗалары игътибарына

«Үлчәмнәрнең бердәмлеген тәэмин итү турында»гы 102нче Федераль закон, куркыныч җитештерү объектларының сәнәгый иминлеге өлкәсендәге Федераль нормалар һәм кагыйдәләр таләпләре нигезендә, газ белән эшли торган котельныйлар һәм топкаларда урнаштырылган углерод оксиды һәм табигый газ сигнализаторлары ел саен тикшерелергә тиеш.

Җылыту сезонына әзерлек барышында барлык котельный хуҗаларына үз вакытында, май-июль айларында, сигнализаторларны «Татарстан Республикасында стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар үткәрү буенча дәүләт төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесенә тикшерүгә бирергә киңәш итәбез. Җаен тикшерү эш атнасы дәвамында үткәрелә, август-сентябрь айларында, мөрәҗәгатьләрнең саны артуга бәйле рәвештә, аның вакыты 4 атна тәшкил итәргә мөмкин! Сигнализаторлар түбәндәге адреслар буенча кабул ителә:

Казан, Журналистлар урамы, 24, приборлар кабул итү бүлеге, тел. (843) 279-59-09, 291-08-60
Чаллы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 61, тел. (8552) 59-20-28, 35-44-47
Әлмәт, Герцен урамы, 86, тел. (8553) 43-18-98, 43-18-95
Түбән Кама, Кайманов урамы, 16/1, тел. (8555) 47-74-29
Чистай, Вәлиев урамы, 4в, тел. (84342) 5-21-00

СИГНАЛИЗАТОРЛАР УРНАШТЫРЫЛГАН УРЫНГА БАРЫП КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРЕЛҮЕ ДӘ ИХТИМАЛ

реклама

АФИША
15-21 МАЙ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

15 май «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фосе)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум
16 май «Искән җилләр көенә» (З.Хәким)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
17 май «Көтәм сине...» (И.Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
20 май «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
21 май «Палата №6» (А.Чехов) (КДМИ студентларының диплом эше)
Башлана: 17.30
Билет бәясе: 100 сум
21 май «KAZAN» бию ансамбле
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 500-1500 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

15 май «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: 18.30
16 май «Кияүләр» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
17 май «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
18 май «Назлы кияү» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
21 май «Әллә язмыш, әллә ялгыш...» (автор – Н.Нестерова, И.Хафизов тәрҗемәсе)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 300-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

17 май «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла)
Башлана:13.00
18 май «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай, Г.Рәхим инсц.)
Башлана: 11.00
19 май «Су анасы» (Г.Тукай, З.Хөснияр инсц.)
Башлана: 13.00
20 май «Дюймовочка» (Г.Х.Андерсен, инсц. Л.Кожевникова)
Башлана: 11.00, 13.00
20 май «Не хочу, не буду!»
Башлана: 11.00
21 май «Буратино» (А.Толстой, инсц. Р.Давыдова)
Башлана: 11.00, 13.00
21 май «Котбетдин мажаралары»
Башлана: 15.00
Билет бәясе: 250-600 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

22 май «Мунча ташы»
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1200 сум
20 май Мини-Мисс Татарстан – 2017
Башлана: 16.00
Билет бәясе: 500-1000 сум

МЕГА СӘҮДӘ ҮЗӘГЕ
(ҖИҢҮ ПРОСПЕКТЫ, 141)

20 май «Яшел фитнес»
Башлана: 18.00
21 май «Яшел фитнес»
Башлана: 10.00
Керү ирекле

АЛАФУЗОВ ФАБРИКАСЫ
(ГЛАДИЛОВ, 55А)

19 май Алафузов маркет – төрле иллардән килгән товарларны сатып алу мөмкинлеге
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 100 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

СПОРТ

ВЕЛОУЗЫШ. Чаллы спортчысы Илнур Зәкәрин дөрәҗәле «Джиро д'Италия» күп көнлек ярышларының дүртенче этабында икенче урын яулады. Ул – илнең «Катюша» командасы велоузышчысы.

Финишка 20 чакрым ара кала, Илнур Зәкәрин, егылса да, көрәшне дәвам итә алды. «Бернинди имгәнүләр дә булмады, сыдырылган урыннар гына. Бүген беренче килүне максат итеп куймаган идем, узыш шулайрак килеп чыкты», – ди Илнур узыштан соң.

Әлеге уңышыннан соң 27 яшьлек спортчы генераль квалификациядә 14нче урынга урнашты. Ул лидердан 14 секундка калыша.

ТХЭКВАНДО. Татарстан егете Рафаэль Камалов 19-30 август көннәрендә Тайбэй шәһәрендә узачак бөтендөнья җәйге Универсиада ярышларында катнашачак. Бу хокукка егет 5-8 май көнне студентлар арасында узган тхэквандо буенча бөтенроссия ярышларында беренче урын алып ия булды. Ярышларда илнең 30 төбәгеннән барлыгы 88 югары уку йорты катнашкан.

ХОККЕЙ. Танылган хоккей белгече, Канадада Хоккей академиясенә нигез салган Даниэль Бохнер нәни «ак барс»чыларга дәрес бирде. Яшь спортчылар ул өйрәткән күнекмәләрне 8-12 май көннәрендә «АК БАРС ХОККЕЙ АКАДЕМИЯСЕ» лагерендә өйрәнә алды. Белгеч аеруча да спортчыларның шуу техникасына, баланска һәм кул эшенә басым ясады. Биредә «Ак Барс», «Динамо» (Казан), «Нефтьче» (Әлмәт) хоккей клубларыннан тыш, Мәскәү, Санкт-Петербург, Тверь кебек шәһәрләрдән дә килүчеләр бар иде.

СУГА СИКЕРҮ. 3-7 май көннәрендә Казанда суга сикерү буенча Россия чемпионаты узды. Биредә илнең 13 төбәгеннән 81 спортчы катнашты, 13 комплект медаль уйнатылды.

Медаль зачетында Татарстан командасы бер алтын, ике көмеш, өч бронза медаль алып, бишенче урынга ия булды. Пенза спортчылары – беренче. Икенче, өченче урыннарны Мәскәү белән Санкт-Петербург бүлеште.

Татарстан спортчысы Никита Шлейхер ярышларда иң көчле спортчыларның берсе булды. Республикага барлык медальләрне ул яулады дисәң дә була. Аның Юлия Тимошинина белән дуэты күпләрне сокландырды. Мәскәү кызы белән чыгышында Никита алтын медаль яулады.

ФУТБОЛ. «Казан-Арена» стадионында узачак «Рубин» белән ЦСКА матчын бушка карау өчен 20 мең кеше гариза җибәргән.

– Әлегә без уенга 20 мең кеше җыйдык. Араларында 2,5 мең кеше – ЦСКА җанатарлары. Мәскәүдән оешкан төркемнәр киләчәк. Без башкала клубы белән элемтәдә торабыз. Бу уен стадионны Конфедерация Кубогы алдыннан сынау матчы булачак. Стадионның барлык системалары эшчәнлеген тикшерү өчен, без күбрәк кеше җыярга тиеш. Аншлаг булыр дип уйлыйм. Һәммәгезне Россия чемпионатының лидерларының берсе белән булган матчка чакырам, – диде Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов.

Исегезгә төшерәбез, матч 17 май көнне булачак. Теләгән һәркем анда җанатар паспорты белән килә ала. Тест матчына алынган паспорт белән конфедерация Кубогының башка уеннарына да кереп булачак. Дәрес, аларына билет алу кирәк булачак. Билетларның 50 проценты инде сатылып беткән. Иң популяр матч булып Россия – Мексика уены санала икән.

Җанатар паспортын интернет аша рәсмиләштерергә дә мөмкин. Моның өчен «Рубин фанс» сайтында анкета тутырырга кирәк. Анарның кесә телефонына код киләчәк. Шул код белән күрсәтелгән сайтта теркәләсең һәм әзер паспортны Бауман урамы, 44/8 адресы буенча барып алырга кирәк булачак. Әлеге паспортларны бирә торган өстәмә үзәкләр дә булдырылыр дип көтелә.

ДЖИУ-ДЖИТСУ. 14 майда Казанның «Ак Барс» көрәш сараенда джиу-джитсу буенча Шиһабетдин Мәрҗани кубогына Бөтенроссия турниры узачак. Көч сынашулар джиу-джитсуның Не-Ваза төре буенча үткәрелә. Турнирны Үзәкләштерелгән дини оешма – Татарстан Мөселманнарының диния нәзарәте, республиканың Джиу-джитсу федерациясе, «ДУМ РТ Хадж» оешмасы, Татарстанның Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Россиянең Джиу-джитсу федерациясе һәм «Ак Барс» көрәш сарае оештыра.

Ярышларда ир-ат һәм хатын-кыз җыелма командалары катнаша. Ир-егетләр 62, 69, 77, 85, 94 һәм 94 килограммнан югары авырлыкта көч сынашса, хатын-кызлар өчен 57, 63, 70 һәм 70 килограммнан югары авырлык каралган. Ир-егетләр арасындагы көч сынашулар ике версия буенча: зәңгәр һәм ак билбау ияләре арасында үтә. Турнирның приз фонды шәхси-команда Кубогы һәм медальләр генә түгел, ә ир-атлар арасында да хаҗга юллама да уйнатыла. Моның өчен спортчының Татарстаннан мөселман кешесе булуы, моңа кадәр хаҗ сәфәре кылмаган булуы шарт.

Турнирга Чувашия, Башкортстан, Ульяновск, Самара өлкәсе һәм Әзәрбайҗаннан да спортчылар килүе көтелә.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1646. Гомуми тираж – 6043.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 711. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан, Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы